# ТАТАРСТАН
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 4*
*апрель*
*(I өлеш)*
*2013*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
2013

**ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ:**
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

Формат 60x84$^{1}/_{16}$. Тираж 95 экз.

© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, 2013

Эчтәлек

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

561. «Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ....................................................17

562. «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..........................................18

563. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* .........................................................................20

564. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ...21

565. «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..................22

566. «Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..........................23

567. «Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Респуб-

ликасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..............................24
568. «Татарстан Республикасы Казан шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..........................47
569. «Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» *Татарстан Республикасы Законы* ..............................90
570. «Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырыгынчы утырышы көн тәртибе турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..........................................................121
571. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..............................................................128
572. «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2012 елгы эшчәнлеге турында хисап хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..............................................................130
573. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 8[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 480-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........................131
574. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 8[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 480-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .......................132
575. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 8[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында

(480-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...132
576. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 477-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...133
577. «Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 452-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...134
578. «Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (452-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..134
579. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 444-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...135
580. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 458-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..135
581. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм референдумнар турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 466-4 номерлы Татарстан Республикасы зако-

ны проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...............................................136
582. «Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 470-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..............................................................................137
583. «Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (470-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...............................................138
584. «Биектау муниципаль районының Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү, аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 1443-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .......................................139
585. «Биектау муниципаль районының Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү, аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында

(1443-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................................................140

586. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 5.1 һәм 5.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 481-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...141

587. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 489-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................................................141

588. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (489-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................................................142

589. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 488-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........142

590. «Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 472-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ......143

591. «Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (472-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...144

592. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 486-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты ту-

рында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................................................................144
593. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (486-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................................................................145
594. «Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 482-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .....145
595. «Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (482-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .....146
596. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 19 статьясына үзгәреш кертү турында» 478-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .......147
597. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 19 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (478-4 номерлы проект)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................................................................147
598. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»

485-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................................................................148
599. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 463-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .....148
600. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................................................................149
601. «Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкиле Е.А. Кулешовның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................................................................150
602. «Россия Федерациясе Җинаять кодексының 282[1] һәм 282[2] статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...............................150
603. «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» 229085-6 номерлы федераль закон проекты турында (вазыйфа биләүгә конкурста катнашучы затларны эш белән тәэмин итүдә эш бирүчеләрнең ярдәме хакында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ......151
604. «Балалары булган гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 217934-6 номерлы федераль закон проекты турында (ана (гаилә) капиталы акчалары исәбеннән сатып алына торган торак урынына таләпләр билгеләү хакында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..........152

605. «Гражданнарның ташламалы категорияләрен шифаханә-курорт юлламалары белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенә Кабарда-Балкар Республикасы Парламенты мөрәҗәгате хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................................................................153
606. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» Федераль законның 11 статьясына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын кертү буенча Архангельск өлкә депутатлары Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..............................................153
607. «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлардагы урыннар һәм торак йортлар милекчеләренә һәм файдаланучыларына коммуналь хезмәт күрсәтү кагыйдәләрен куллануга коммуналь хезмәтләрнең барлык төрләре буенча гомуми йорт ихтыяҗлары өчен нормативларны куллану өлешендә мораторий кертү турында Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгына Коми Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .........154
608. «Россия Федерациясе Пенсия фондына шәхси эшкуарлар түли торган иминият кертемнәре күләмнәренең кимүе өлкәсендә федераль законнарны үзгәртү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Төньяк Осетия – Алания Республикасы Парламенты мөрәҗәгате турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .............................................155
609. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексы» 246960-6 номерлы федераль закон проекты турында (гомуми юрисдикциядәге судлар тарафыннан административ суд эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен җайга салу)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .......................................155
610. «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга һәм

Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 232608-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе гражданнары, карау өчен, үз мөрәҗәгатьләрен җибәрергә хокуклы адресатлар исемлеген киңәйтү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................................................................156
611. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 248585-6 номерлы федераль закон проекты турында (ветеринария өлкәсендә законнарны бозган өчен административ хокук бозулар составларын төгәлләштерү һәм җаваплылыкны көчәйтү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...................157
612. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә аерым федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү турында» 246969-6 номерлы федераль конституциячел закон проекты хакында (Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын кабул итүгә бәйле рәвештә федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..................................157
613. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 246965-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын кабул итүгә бәйле рәвештә федераль законнарга үзгәрешләр кертү)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................................................................158
614. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең башка закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 241591-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясендә эшкә рөхсәт яисә патент нигезендә хезмәт эшчәнлекләрен гамәлгә ашырырга ниятләгән чит ил гражданнарын һәм граж-

данлыгы булмаган затларны салым органнарында исәпкә кую механизмын камилләштерү өлешендә, шулай ук Федераль миграция хезмәте органнары һәм Россия Федерациясе салым органнары арасында тиешле белешмәләрне алмашу процедураларын һәм тәртибен оптимальләштерү максатларында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....159

615. «Корал турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Кабарда-Балкар Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................................................................160

616. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 һәм 8.37 статьяларына һәм Россия Федерациясе Җинаять кодексының 256 статьясына балыкчылык һәм су биологик ресурсларын саклау хакында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү максатларында үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Сахалин өлкә Думасының закон чыгару инициативасы хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........161

617. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...............................................162

618. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 362 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 249584-6 номерлы федераль закон проекты хакында (кыйммәтле транспорт чаралары милекчеләренә салым йөкләмәсен арттыру өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ......162

619. «Салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычны җайга салу мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 227758-6 номерлы федераль закон проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .....................163
620. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның $26^3$ статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мәскәү өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ............................................164
621. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 250003-6 номерлы федераль закон проекты турында (монополиягә каршы законнарны бозган өчен административ җаваплылык билгели торган нигезләмәләрне төгәлләштерү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .........165
622. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын гамәлгә кертү тәртибе турында» 246963-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексы кабул ителгәннән һәм гамәлгә кертелгәннән соң гавами хокук мөнәсәбәтләреннән барлыкка килә торган эшләрне судларда карау тәртибе)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...........165
623. «Полиция турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 242420-6 номерлы федераль закон проекты турында (хәрби комиссариатка килү өчен чакыру кәгазьләре бирү максатында гражданнарның яшәү урыннарын билгеләү буенча полициягә йөкләмә бирү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ......................166
624. «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законның 13 ста-

тьясына үзгәреш кертү хакында» 241971-6 номерлы федераль закон проекты турында (аерым категория гражданнарның дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләре тарафыннан чиратсыз рәвештә шәхси кабул ителү хокукын билгеләү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................167
625. «Мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контроле турында һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга ярдәм итү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 239149-6 номерлы федераль закон проекты турында (сәяси партияләргә һәм дини берләшмәләргә иҗтимагый күзәтү комиссиясе составына үз кандидатларын чыгару хокукын бирү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................168
626. «Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашулары турында» 238654-6 номерлы федераль закон проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................168
627. «Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашулары мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 238639-6 номерлы федераль закон проекты хакында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....169
628. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 236741-6 номерлы федераль закон проекты турында (хәрәкәт итүне билгеләнгән тизлектән арттырган өчен җаваплылыкны төгәлләштерү хакында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .....169
629. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.22 статьясына үзгәреш кертү хакында» 234583-6 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чараларын дәүләт теркәвенә кую кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыкны арттыру хакында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ....................170
630. «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»

232405-6 номерлы федераль закон проекты турында (төшенчәләр аппаратын киңәйтү һәм шимбә, якшәмбе һәм бәйрәм көннәрендә иртәнге вакытта тавыш йогынтысының билгеләнгән санитар нормаларының гамәлдә булуын тарату өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .........................171
631. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 231581-6 номерлы федераль закон проекты турында (гавами чараларны оештыручыларга һәм анда катнашучыларга җаваплылыкны төгәлләштерү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...171
632. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 231292-6 номерлы федераль закон проекты турында (җир законнарын бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .....................................................................172
633. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 231281-6 номерлы федераль закон проекты турында (коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү күләмен исәпләү тәртибен бозган өчен җаваплылык билгеләү хакында)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ...................................................................173
634. «Полиция турында» Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлешенә үзгәреш кертү хакында» 223180-6 номерлы федераль закон проекты турында (хәрби исәпкә куелудан, хәрби хезмәткә яисә хәрби җыеннарга чакырудан, хәрби хезмәт яисә хәрби җыеннар узудан качып йөрүче гражданнарны эзләү һәм кулга алуны гамәлгә ашыру буенча полициягә йөкләмә бирү өлешендә)» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* .....................................................................173
635. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Х.Г. Миргалимовның депутат гарызнамәсе турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..174

## II
## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

636. «Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырыгынчы утырышын чакыру турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ....175

637. «Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырыгынчы утырышы каравына кертелүче мәсьәләләр турында *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ..175

638. «С.М. Захарованы «Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» мактаулы исемен бирүгә тәкъдим итү турында» *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ..180

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 561. «Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» 2002 елның 15 октябрендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 10; 2003, № 9 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендә «якындагы сессиясендә» сүзләрен «якындагы утырышында» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җәмәгатьчелек вәкиленең вәкаләтләре түбәндәге нигезләр буенча вакытыннан алда туктатыла:

1) җәмәгатьчелек вәкиленең вәкаләтләрен туктатуы турында язма гаризасы;

2) җәмәгатьчелек вәкиленең дәүләт яисә муниципаль хезмәткә керешүе, шулай ук аның дәүләт яисә муниципаль вазыйфа биләве;

3) җәмәгатьчелек вәкиленең адвокат статусын алуы;

4) җәмәгатьчелек вәкиленең нотариус итеп билгеләнеп куелуы;

5) җәмәгатьчелек вәкиленең оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә оешманың яисә учреждениенең җитәкчесе итеп билгеләнеп (сайланып) куелуы;

6) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылу;

7) судның гаепләү карарының закон көченә керүе;

8) җәмәгатьчелек вәкиленең хокукый сәләте чикле булу турында йә аны хокукый сәләтсез дип тану турында суд карарының закон көченә керүе;

9) җәмәгатьчелек вәкилен хәбәрсез югалган дип тану йә закон көченә кергән суд карары нигезендә вафат булган дип игълан итү;

10) җәмәгатьчелек вәкиленең үлеме.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Үзенең яман атын чыгарырлык гамәлләр кылган, шулай ук җәмәгатьчелек вәкиле вазыйфаларын системалы рәвештә башкармаган очракта җәмәгатьчелек вәкиленең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылырга мөмкин.»;

в) 2 өлештә «якындагы сессиядә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының якындагы утырышында» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 11 апреле
№ 25-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 562. «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII но-

мерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 маендагы 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 11; 2005, № 5; 2009, № 6; 2012, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«яшь гражданнар (яшьләр) – 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге затлар;»;

б) бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 10 статьяда:

а) исемендә «һәм яшьләр» сүзләрен «, яшьләр һәм балалар» сүзләренә алмаштырырга;

б) беренче һәм икенче абзацларда «һәм яшьләр» сүзләрен «, яшьләр һәм балалар» сүзләренә алмаштырырга;

в) өченче һәм бишенче абзацларда «яшьләр» сүзеннән соң «һәм балалар» сүзләрен өстәргә;

3) 11 статьяда:

а) исемендә «яшьләр» сүзеннән соң «һәм балалар» сүзләрен өстәргә;

б) текстта «яшьләр» сүзеннән соң «һәм балалар» сүзләрен өстәргә;

4) 14 статьяның икенче абзацында «һәм яшьләр» сүзләрен «, яшьләр һәм балалар» сүзләренә алмаштырырга;

5) 15 статьяның беренче абзацында «яшьләр» сүзеннән соң «һәм балалар» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 11 апреле
№ 26-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 563. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1), 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яки туктату – Федераль законның 30 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларда, торак пунктлар чикләре эчендәге региональ, җирле әһәмиятле автомобиль юлларына карата халыкара спорт чараларын уздыру чорында да билгеләнергә мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 11 апреле
№ 27-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 564. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 3; Ватаным Татарстан, 2012, 6 октябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның беренче өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү системасын булдыру, аны эксплуатацияләүне һәм үстерүне тәэмин итү.»;

2) 10 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү системасын булдыруда, эксплуатацияләүдә һәм үстерүдә катнашу.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 11 апреле
№ 28-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 565. «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2003 елның 6 августындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2011, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«7 статья.** «Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы» – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы актларын, шулай ук башка актларны бастырып чыгару өчен билгеләнгән рәсми вакытлы басмасы. «Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы» структурасы, аны әзерләү, чыгару һәм тарату тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы тарафыннан билгеләнә.»;

2) 8 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 9 статьяның беренче өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 11 апреле
№ 29-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 566. «Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында» 2005 елның 30 декабрендәге 138-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2007, № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 1, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 12 (I өлеш), 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Россия Федерациясе Торак кодексының 159 статьясындагы 2 өлешенең 1 – 3 пунктларында күрсәтелгән затлар өчен торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр бәясенең төбәк стандарты күләме төзекләндерү дәрәҗәсе, конструктив һәм техник параметрлары муниципаль берәмлектәге уртача шартларга туры килә торган күпфатирлы йортлардагы торак урыннарында социаль наем шартнамәләре буенча яши торган яллаучыларның торак урыныннан файдалануы өчен түләү (наем өчен түләү) күләменнән, бу яллаучылар өчен торак урынын карап тотуга һәм ремонт ясауга түләү күләмен исәпләп чыгару өчен кулланыла торган бәяләр күләменнән, коммуналь хезмәт күрсәтүләрне куллануның бу яллаучылар өчен коммуналь хезмәт күрсәтүләргә түләү күләмен исәпләп чыгару өчен кулланыла торган бәяләреннән, тарифларыннан һәм нормативларыннан чыгып билгеләнә. Торак урыннары милекчеләре өчен торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр бәясенең төбәк стандарты күләме бу яллаучылар өчен торак урынын карап тотуга һәм ремонт ясауга түләү күләмен исәпләп чыгару өчен кулланыла торган бәяләр күләменнән, капиталь ремонт ясауга кертемнең минималь күләменнән (Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә

капиталь ремонт ясауга кертемнәр түләгән очракта), коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен кирәкле чималга бәяләрдән, тарифлардан һәм бу яллаучылар өчен коммуналь хезмәт күрсәтүләргә түләү күләмен исәпләп чыгару өчен кулланыла торган коммуналь хезмәт күрсәтүләрне куллану нормативларыннан чыгып билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 13 апреле
№ 30-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 567. Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Тәтеш муниципаль районы составындагы түбәндәге муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп корырга:

1) «Олы Шәмәк авыл җирлеге»н һәм «Кече Шәмәк авыл җирлеге»н әлеге җирлекләрдә яшәүче халыкның аларның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Олы Шәмәк авылы булган «Олы Шәмәк авыл җирлеге»нә берләштерү юлы белән;

2) «Keләш авыл җирлеге»н һәм «Тоншерма авыл җирлеге»н әлеге җирлекләрдә яшәүче халыкның аларның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Келәш авылы булган «Келәш авыл җирлеге»нә берләштерү юлы белән;

3) «Лаптевка авыл җирлеге»н һәм «Монастырский авыл җирлеге»н әлеге җирлекләрдә яшәүче халыкның аларның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Монастырский авылы булган «Монастырский авыл җирлеге»нә берләштерү юлы белән;

4) «Нармонка авыл җирлеге»н һәм «Чинчурино авыл җирлеге»н әлеге җирлекләрдә яшәүче халыкның аларның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Нармонка авылы булган «Нармонка авыл җирлеге»нә берләштерү юлы белән;

5) «Богдашкино авыл җирлеге»н, «Ивановка авыл җирлеге»н һәм «Урюм авыл җирлеге»н әлеге җирлекләрдә яшәүче халыкның аларның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Пролей-Каша авылы булган «Урюм авыл җирлеге»нә берләштерү юлы белән.

**2 статья**

1. Яңа төзелгән «Олы Шәмәк авыл җирлеге», «Келәш авыл җирлеге», «Монастырский авыл җирлеге», «Нармонка авыл җирлеге», «Урюм авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең (алга таба – яңа төзелгән муниципаль берәмлекләр) беренче чакырылыш вәкиллекле органнары депутатларының һәм беренче башлыкларының вәкаләтләре чорын биш ел дип билгеләргә.

2. Һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең беренче чакырылыш вәкиллекле органнарындагы депутатлар санын ун кеше тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сайлауларны билгеләү, сайлауларны әзерләү һәм үткәрү законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

**3 статья**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ

номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә җирле референдумнарда кабул ителә торган яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары структурасы турындагы карарларында башкасы билгеләнмәгән булса, түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең беренче башлыгы әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан яшерен тавыш бирү юлы белән үз составыннан сайлап куела.

Һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутаты, вәкиллекле орган депутатларының билгеләнгән саныннан яртысыннан артыграгы аны хуплап тавыш бирсә, бу муниципаль берәмлекнең сайлап куелган башлыгы дип санала.

Һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлек башлыгын сайлап куйганчы, бу муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары утырышын вәкиллекле органның яше буенча иң өлкән депутаты ача һәм алып бара;

2) һәрбер яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең сайлап куелган башлыгы бу муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен башкара.

**4 статья**

«Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 12 (IV өлеш); 2010, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3 статья.** «Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керә торган түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен карта-схема (әлеге Законга 1 нче кушымта) һәм чикләрнең картографик тасвирламасы (әлеге Законга 4 – 35 нче кушымталар) нигезендә билгеләргә, аларга авыл җирлеге статусын бирергә һәм административ үзәкләрен расларга:

Алабирде авыл җирлеге: Алабирде авылы (административ үзәк);

Байраш авыл җирлеге: Байраш авылы (административ үзәк);

Бакырчы авыл җирлеге: Бакырчы (административ үзәк), Үтәмеш, Татар Чагылдымы, Чуаш Чагылдымы, Чуаш Чурапаны авыллары, Татар Чурапаны поселогы;

Бидәңге авыл җирлеге: Татар Бидәңгесе авылы (административ үзәк);

Бессоново авыл җирлеге: Бессоново (административ үзәк), Югары Тархан авыллары;

Зур Әтрәч авыл җирлеге: Зур Әтрәч (административ үзәк), Кече Әтрәч, Никифоровка авыллары;

Олы Тархан авыл җирлеге: Олы Тархан (административ үзәк), Түбән Тархан авыллары, Мәмәй, Төкәш поселоклары;

Олы Тормы авыл җирлеге: Олы Тормы (административ үзәк), Кече Тормы, Чолы авыллары;

Олы Шәмәк авыл җирлеге: Олы Шәмәк (административ үзәк), Кече Бисәр, Кече Шәмәк, Кече Фролово авыллары, Победа поселогы;

Жуково авыл җирлеге: Жуково авылы (административ үзәк), Иоково, Кызыл Тархан, Берлек, Яңа Сумароков авыллары;

Килдеш авыл җирлеге: Килдеш (административ үзәк), Кызыл Күл авыллары;

Киртәле авыл җирлеге: Киртәле (административ үзәк), Кадыш, Васильевка, Красный Восток авыллары;

Келәш авыл җирлеге: Келәш (административ үзәк), Тоншерма авыллары;

Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге: Кошки-Новотимбаево (административ үзәк), Яңа Льяшево Пүчинкәсе, Ивановка, Максимовка, Салмановка, Иске Колмәт, Чуаш Тайбасы авыллары;

Льяшево авыл җирлеге: Льяшево (административ үзәк), Олы Бисәр, Ямбакты авыллары;

Монастырский авыл җирлеге: Монастырский (административ үзәк), Лаптевка, Баймәт, Долгая Поляна, Ильинский авыллары;

Нармонка авыл җирлеге: Нармонка (административ үзәк), Зеленовка, Колунец, Чинчурино, Кушкуй авыллары;

Сөендек авыл җирлеге: Сөендек (административ үзәк), Башчы авыллары;

Урюм авыл җирлеге: Пролей-Каша (административ үзәк), Богдашкино, Кашка, Урюм, Ивановка авыллары, Пищемар поселогы;

Федоровка авыл җирлеге: Федоровка (административ үзәк), Алекина Поляна, Удельное Нечасово, Кызыл Йолдыз, Красное Нечасово авыллары.»;

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

**"Тәтеш муниципаль районы"**
**муниципаль берәмлеге составына керә торган**
**муниципаль берәмлекләрнең чикләре**
**карта-схемасы**




**Шартлы билгеләр**

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
- 35 - тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

**Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы**

| | |
|---|---|
| 50(3) - 67(4) | - Ульяновск өлкәсе |
| 67(4)-19(36) | - Буа муниципаль районы |
| 2(35)-19(36) | - Апас муниципаль районы |
| 28(34)-2(35) | - Кама Тамагы муниципаль районы |
| 50(3)-28(34) | - Спас муниципаль районы |

«Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керә торган шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схема-дагы № | Муниципаль берәмлекләр |
|---|---|
| 1 | Тәтеш шәһәре |
| 2 | Алабирде авыл җирлеге |
| 3 | Байраш авыл җирлеге |
| 4 | Бакырчы авыл җирлеге |
| 5 | Бидәңге авыл җирлеге |
| 6 | Бессоново авыл җирлеге |
| 7 | Зур Әтрәч авыл җирлеге |
| 8 | Олы Тархан авыл җирлеге |
| 9 | Олы Тормы авыл җирлеге |
| 10 | Олы Шәмәк авыл җирлеге |
| 11 | Жуково авыл җирлеге |
| 12 | Килдеш авыл җирлеге |
| 13 | Киртәле авыл җирлеге |
| 14 | Келәш авыл җирлеге |
| 15 | Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге |
| 16 | Льяшево авыл җирлеге |
| 17 | Монастырский авыл җирлеге |
| 18 | Нармонка авыл җирлеге |
| 19 | Сөендек авыл җирлеге |
| 20 | Урюм авыл җирлеге |
| 21 | Федоровка авыл җирлеге |

3) 3 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «Ивановка,» сүзен төшереп калдырырга, «Нармонка» сүзеннән соң «, Урюм» сүзен өстәргә;

б) дүртенче абзацта «Ивановка һәм Нармонка» сүзләрен «Нармонка һәм Урюм» сүзләренә алмаштырырга;

в) җиденче абзацта «Ивановка» сүзен «Урюм» сүзенә алмаштырырга;

г) сигезенче абзацта «Ивановка» сүзен «Урюм» сүзенә алмаштырырга;

4) 10 нчы кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 11 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «Лаптевка,» сүзен төшереп калдырырга;

б) бишенче абзацта «Лаптевка» сүзен «Монастырский» сүзенә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зур Әтрәч авыл җирлеге чиге Монастырский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 3 нче тоташу ноктасыннан алып гомуми юнәлештә көньяк-көнбатышка таба «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәр участок урманчылыгындагы 47 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап инешкә кадәр уза, алга таба шушы инеш агымы буенча 670 м аска таба ул башка инешкә койган җиргә кадәр уза, аннары шушы инеш агымы буенча 560 м өскә таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м көньяк-көнчыгышка таба, 1,5 км көньяк-көнбатышка таба уза, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап һәм 200 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң гомуми юнәлештә 250 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Тәтеш – Кама Тамагы» – Монастырский – Лаптевка автомобиль юлын кисеп үтеп, 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м урман массивы буйлап һәм 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 50 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Тәтеш – Кама Тамагы» – Монастырский – Лаптевка автомобиль юлына кадәр уза, аннары әлеге автомобиль юлы буйлап 950 м көньякка таба бара, шуннан соң көнбатышка таба борыла һәм 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 2 нче урман кварталына кадәр бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 2,0 км «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 2 нче, 4 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 150 м «Тәтеш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урман-

чылыгындагы 4 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап «Тәтеш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Зур Әтрәч, Льяшево һәм Монастырский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Монастырский авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

б) 13 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «, Кече Шәмәк» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Олы Тормы авыл җирлеге чиге Олы Шәмәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олы Тормы, Олы Шәмәк һәм Льяшево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Шәмәк авылыннан 2,0 км көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып 1,1 км төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм, Чукасы инешен кисеп үтеп, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Тормы елгасына кадәр уза, аннары Тормы елгасы агымы буенча 12,3 км өскә таба инешкә кадәр бара, аннары инеш агымы буенча 2,3 км өскә таба Олы Тормы, Олы Шәмәк авыл җирлекләре һәм Апас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кече Фролово авылыннан 2,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.»;

в) бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

7) 14 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәтеш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль
берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
14 нче кушымта

## Тәтеш муниципаль районының «Олы Шәмәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

ноктага кадәр бара, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнчыгыш юнәлештә Кол Гали урамындагы 1 нче йортның көнчыгыш ягы буйлап автомобиль юлы буенча уза, аннары уңга борыла һәм Завойский урамындагы 2, 8 һәм 12 нче йортларның көньяк ягы буйлап Юлиус Фучик урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Юлиус Фучик урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Кол Гали урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Кол Гали урамының күчәр сызыгы буйлап 14 нче йортның 2 нче корпусы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көньяк-көнбатыш юнәлештә Кол Гали урамындагы 14 нче һәм Сафиуллин урамындагы 17 нче йортлар буендагы автомобиль юлы буенча Сафиуллин урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Сафиуллин урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Комиссар Гәбишев урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба Комиссар Гәбишев урамының күчәр сызыгы буйлап, Алтан торак пункты территориясен кертеп, Кол Гали урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм Кол Гали һәм Үзәк урамнарының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Салмачы торак пунктының көнчыгыш кырыена кадәр уза, алга таба уңга борыла һәм көнбатыш юнәлештә Салмачы торак пунктының көньяк-көнчыгыш, көньяк кырыйлары һәм Алтан торак пунктының көньяк кырые буйлап Комиссар Гәбишев урамындагы 4 нче йортның төньяк-көнчыгыш ягы янында әлеге урамның күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Комиссар Гәбишев урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Имәнлек һәм Рихард Зорге урамнарының күчәр сызыклары белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба төньякка таба Рихард Зорге урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Җиңү проспекты һәм Рихард Зорге урамының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктага кадәр уза.

**10 нчы суд участогы**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Идел буе районы буенча җәмәгать судьясының 10 нчы суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең

бер өлеше керә, аның чиге Казан шәһәре Идел буе һәм Совет районнарының административ чигендә урнашкан Академик Завойский һәм Юлиус Фучик урамнарының күчәр сызыклары кисешкән ноктадан алып көньяк-көнбатышка таба Юлиус Фучик урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Кол Гали урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Кол Гали урамының күчәр сызыгы буйлап 14 нче йортның 2 нче корпусы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көньяк-көнбатыш юнәлештә автомобиль юлы буйлап, Гол Гали урамындагы 14 нче һәм Сафиуллин урамындагы 17 нче йортларны кертеп, Сафиуллин урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Сафиуллин урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Комиссар Гәбишев урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Комиссар Гәбишев урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Кол Гали урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм Кол Гали һәм Үзәк урамнарының күчәр сызыклары буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Казан шәһәре Идел буе һәм Совет районнарының административ чигенә кадәр уза, алга таба сулга борыла һәм төньяк-көнчыгыш юнәлештә Казан шәһәре Идел буе һәм Совет районнарының административ чиге буенча, Вишневка һәм Восточный торак пунктларын кертеп, Академик Завойский һәм Юлиус Фучик урамнарының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктага кадәр уза.

## 11 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Идел буе районы буенча җәмәгать судьясының 11 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Гарифьянов, Профессор Камай һәм Хөсәен Мәүлетов урамнары киселешендә урнашкан ноктадан алып көнчыгышка таба Гарифьянов урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Рихард Зорге урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аны Рихард Зорге урамындагы 57 нче йортның көнбатыш почмагы районында кисеп үтә, аннары төньяк-көнчыгышка таба туры сызык буенча Рихард Зорге урамындагы 57, 61, 63, 65 нче, Бертуган Касыймовлар урамындагы 86 нчы, 84 нче һәм Җиңү проспектындагы 41 нче, 45 нче

йортлар буенча, Рихард Зорге урамындагы 53 нче, 55 нче, Бертуган Касыймовлар урамындагы 68, 78, 80 нче, 82А һәм Җиңү проспектындагы 47 нче йортларны кертеп, Бертуган Касыймовлар урамының күчәр сызыгы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Бертуган Касыймовлар урамының күчәр сызыгы буйлап Җиңү проспекты һәм Сафиуллин урамының күчәр сызыклары белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба шул ук юнәлештә Сафиуллин урамының күчәр сызыгы буйлап Сафиуллин урамындагы 7 нче йортның көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары сулга борыла һәм урман паркы белән гараж кооперативы арасындагы автомобиль юлы буенча, урман паркы территориясен кертеп, Кол Гали урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньякка таба Кол Гали урамының күчәр сызыгы буйлап Кол Гали урамындагы 1 нче йортның көньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары уңга борыла һәм Кол Гали урамындагы 1 нче йортның көнчыгыш ягы буйлап автомобиль юлы буенча уза, аннары уңга борыла һәм Академик Завойский урамындагы 2, 8 һәм 12 нче йортларның көньяк ягы буйлап, әлеге йортларны кертеп, Юлиус Фучик урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньякка таба Юлиус Фучик урамының күчәр сызыгы буйлап Академик Завойский урамы буйлап уза торган Казан шәһәре Идел буе һәм Совет районнарының административ чигенә кадәр бара, алга таба сулга борыла һәм көнбатыш юнәлештә Казан шәһәре Идел буе һәм Совет районнарының административ чиге буенча Танк һәм Хөсәен Мәүлетов урамнарының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктага кадәр бара, аннары көньякка таба Хөсәен Мәүлетов урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Гарифьянов, Профессор Камай һәм Хөсәен Мәүлетов урамнары киселешендә урнашкан ноктага кадәр уза.»;

4) 7 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Казан шәһәре буенча Татарстан
Республикасы җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында»
Татарстан Республикасы Законына
7 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районы буенча җәмәгать судьясының 1 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Совет мәйданының көньяк ягында Николай Ершов һәм Космонавтлар урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнбатышка таба Николай Ершов урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Искра урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк юнәлештә Искра урамының күчәр сызыгы буйлап Патрис Лумумба урамына кадәр бара, аны кисеп үтә һәм шул ук юнәлештә Шуртыгин урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Курск урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм Курск урамының күчәр сызыгы буйлап Гвардия урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньякка таба Гвардия урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Гадел Кутуй урамының күчәр сызыгы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Гадел Кутуй урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Бохара урамына кадәр бара, алга таба көньяк юнәлештә Бохара һәм Родина урамнарының күчәр сызыклары буйлап, сул якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зонаны кертеп, Родина урамындагы 3 нче йортка кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә Родина урамының күчәр сызыгы буйлап Җиңү проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньякка таба Җиңү проспектының күчәр сызыгы буйлап Җиңү проспектындагы 116А йортның төньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, ан-

нары уңга борыла һәм көнчыгышка таба Минск урамындагы йортлар һәм Ломжа урамындагы йортлар арасындагы автомобиль юлы буенча, Минск урамындагы йортларны кертеп, Юлиус Фучик урамының күчәр сызыгы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньякка таба Юлиус Фучик урамының күчәр сызыгы буйлап Минск урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көнбатышка таба Минск урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Җиңү проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм Җиңү проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Аграр урамы һәм Мамадыш трактының күчәр сызыклары белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары төньяк-көнбатышка таба Аграр һәм Космонавтлар урамнарының күчәр сызыклары буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Совет мәйданының көньяк ягында Николай Ершов урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 2 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районы буенча җәмәгать судьясының 2 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Альберт Камалиев, Академик Сахаров урамнары һәм Җиңү проспектының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Академик Сахаров урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Академик Сахаров урамындагы 12 нче йортның төньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм автомобиль юлы буйлап көнчыгышка таба, Академик Сахаров урамындагы 12 нче, Галия Кайбицкая урамындагы 5, 7, 11 нче йортларны һәм Академик Глушко урамындагы 9 нчы йортның 1 нче корпусын кертеп, Академик Глушко урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньякка таба Академик Глушко урамының күчәр сызыгы буйлап Галия Кайбицкая һәм Тыныч урамнарының күчәр сызыклары белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көнчыгышка таба Тыныч урамының күчәр сызыгы буйлап Магистраль урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм, Магистраль урамының күчәр сызыгы дәвамы булып, туры юнәлештә урман утыртмалары башына кадәр бара, алга таба сулга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә

урман утыртмалары чиге буйлап Зур Клыки торак пунктының көньяк кырые буенча, урман утыртмалары территориясен кертеп, Нокса елгасына кадәр уза, аннары көньякка таба Нокса елгасы үзәне буенча (агым буенча өскә таба) Вознесенское торак пункты кырыена кадәр уза, алга таба көнбатышка таба урман утыртмалары чиге буйлап Вознесенское торак пункты кырые буенча Минск урамындагы 37 нче йортның көнбатыш ягыннан әлеге урамга килеп чыга, аннары шул ук юнәлештә Минск урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Җиңү проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньякка таба Җиңү проспектының күчәр сызыгы буйлап Альберт Камалиев һәм Академик Сахаров урамнарының күчәр сызыклары белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 3 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районы буенча җәмәгать судьясының 3 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Биектау муниципаль районы белән чигендә урнашкан М-7 федераль трассасы һәм Азин урамының кисешү ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба Азин, Мир урамнары һәм Себер трактының күчәр сызыклары буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Нокса елгасы аша автомобиль күперендә урнашкан ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көньякка таба Нокса елгасы үзәне буенча (агым буенча өскә таба), сул ярны кертеп, Каспий урамында урнашкан автомобиль күперенә кадәр уза, алга таба көнчыгышка таба Каспий урамының күчәр сызыгы буйлап «Нокса» бакчачылык ширкәтенә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм Царицыно зираты коймасының төньяк-көнчыгыш ягы буенча, «Нокса» бакчачылык ширкәте территориясен кертеп, Царицынский Бугор торак пункты кырыена кадәр бара, алга таба көнчыгыш юнәлештә Царицынский Бугор һәм Константиновка торак пунктларының төньяк-көнбатыш, төньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш кырыйлары буйлап, бакчачылык җәмгыятьләре һәм ширкәтләре территорияләрен кертеп, 129 нчы йорт янында Мамадыш тракты белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары көнчыгышка таба Мамадыш трактының күчәр сызыгы буйлап М-7 федераль трассасы буйлап уза торган Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Питрәч муниципаль районы белән чигенә кадәр уза, аннары

сулга борыла һәм төньяк юнәлештә Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Питрәч муниципаль районы, аннары Биектау муниципаль районы белән чиге буенча Азин урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза.

### 4 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районы буенча җәмәгать судьясының 4 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Биектау муниципаль районы белән чигендә урнашкан М-7 федераль трассасы һәм Азин урамының кисешү ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба Азин, Мир урамнары һәм Себер трактының күчәр сызыклары буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Академик Арбузов урамы һәм Ямашев проспектының күчәр сызыклары белән кисешү ноктасына кадәр уза, алга таба Ямашев проспектына таба борыла һәм аның күчәр сызыгы буйлап Ямашев проспекты буенча урнашкан Казансу елгасы аша автомобиль күпереннән уза торган Казан шәһәре Совет һәм Яңа Савин районнарының административ чиге белән кисешү ноктасына кадәр уза, алга таба төньяк юнәлештә Казан шәһәре Совет һәм Яңа Савин районнарының, аннары Казан шәһәре Авиатөзелеш районының административ чикләре буйлап М-7 федераль трассасы аша уза торган Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Биектау муниципаль районы белән чигенә кадәр бара, алга таба уңга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге буйлап, Колсәет торак пункты территориясен кертеп, Азин урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза.

### 5 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районы буенча җәмәгать судьясының 5 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Альберт Камалиев, Академик Сахаров урамнары һәм Җиңү проспектының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Академик Сахаров урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Академик Сахаров урамындагы 12 нче йортның төньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан нокта-

га кадәр уза, аннары сулга борыла һәм автомобиль юлы буйлап көнчыгышка таба, Академик Сахаров урамындагы 16 нчы, Рәшит Ваһапов урамындагы 14 нче, 18 нче һәм Академик Глушко урамындагы 15 нче йортларны кертеп, Академик Глушко урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньякка таба Академик Глушко урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Җәүдәт Фәйзи урамына кадәр бара, аннары аның күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Җиңү проспектындагы 194/3 нче йортка (автоүзәк) кадәр уза, аннары сулга борыла һәм автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Җиңү проспектының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр бара, алга таба көньякка таба Җиңү проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Альберт Камалиев һәм Академик Сахаров урамнарының күчәр сызыклары белән кисешү ноктасына кадәр бара.

### 6 нчы суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районы буенча җәмәгать судьясының 6 нчы суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Академик Глушко һәм Тыныч урамнарының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньякка таба Академик Глушко урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Җәүдәт Фәйзи урамына кадәр уза, аннары аның күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Җиңү проспектындагы 194/3 нче йортка (автоүзәк) кадәр уза, аннары сулга борыла һәм автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Җиңү проспектының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр бара, алга таба төньякка таба Җиңү проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Дорожный тыкрыгына кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба Дорожный тыкрыгының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны һәм Кече Клыки торак пунктының шәхси сектор йортларын кертеп, Нокса елгасы аша автомобиль күперенә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм Нокса елгасы үзәне буенча (агым буенча аска таба), уң ярны кертеп, Каспий урамында урнашкан автомобиль күперенә кадәр уза, алга таба көнчыгышка таба Каспий урамының күчәр сызыгы буйлап «Нокса» бакчачылык ширкәтенә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм «Нокса» бакчачылык ширкәте коймасының көньяк-көнбатыш ягы буенча,

Царицыно зираты территориясен кертеп, Царицынский Бугор торак пункты кырыена кадәр бара, алга таба көнчыгыш юнәлештә Царицынский Бугор һәм Константиновка торак пунктларының төньяк-көнбатыш, төньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш кырыйлары буйлап бакчачылык җәмгыятьләре һәм ширкәтләре территорияләре буенча, Царицынский Бугор һәм Константиновка торак пунктлары территорияләрен кертеп, 129 нчы йорт янында Мамадыш тракты белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары көнчыгышка таба Мамадыш трактының күчәр сызыгы буйлап Самосырово зираты коймасының төньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм Самосырово зираты коймасының көнчыгыш һәм көньяк яклары буйлап уза, алга таба көнбатыш юнәлештә Самосырово торак пунктының көньяк кырые буйлап, Самосырово зираты һәм Самосырово торак пункты территорияләрен кертеп, Нокса елгасына кадәр уза, аннары көньякка таба Нокса елгасы үзәне буенча (агым буенча өскә таба), аның сул ярында урнашкан Зур Клыки торак пунктын кертеп, аның көньяк кырыена кадәр уза, аннары уңга борыла һәм Зур Клыки торак пунктының көньяк кырые буйлап Тыныч һәм Магистраль урамнарының кисешү ноктасына кадәр бара, алга таба көнбатышка таба Тыныч урамының күчәр сызыгы буйлап Академик Глушко урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза.

## 7 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районы буенча җәмәгать судьясының 7 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Җиңү проспекты һәм Академик Завойский урамының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньякка таба Җиңү проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Җиңү проспектындагы 116А йортының төньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көнчыгышка таба Минск урамындагы йортлар һәм Ломжа урамындагы йортлар арасындагы автомобиль юлы буенча, Ломжа урамындагы йортларны кертеп, Юлиус Фучик урамына кадәр уза, аны кисеп үтә һәм алга таба шул ук юнәлештә автомобиль юлы буйлап, Юлиус Фучик урамындагы 96 нчы һәм Нокса Авышлыгы урамындагы 11 нче йортларны кертеп, Нокса Авышлыгы урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көньяк-

көнбатышка таба Нокса Авышлыгы урамының күчәр сызыгы буйлап Юлиус Фучик урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньякка таба Юлиус Фучик урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Академик Завойский урамының күчәр сызыгы буйлап уза торган Казан шәһәре Совет һәм Идел буе районнарының административ чигенә кадәр уза, алга таба көнбатышка таба Казан шәһәре Совет һәм Идел буе районнарының административ чиге буйлап Җиңү проспекты һәм Академик Завойский урамының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктага кадәр бара.

## 8 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районы буенча җәмәгать судьясының 8 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Даурия һәм Карбышев урамнарының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнчыгышка таба Даурия урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Гадел Кутуй урамының икенче дәрәҗәдәге юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Гадел Кутуй урамының икенче дәрәҗәдәге автомобиль юлы буйлап, уң якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, 86 нчы йортның 2 нче корпусының көньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә автомобиль юлы буйлап Бохара урамына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Бохара урамының күчәр сызыгы буйлап Родина урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньякка таба Родина урамының күчәр сызыгы буйлап Родина урамындагы 3 нче йортка кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә Родина урамының күчәр сызыгы буйлап Җиңү проспекты белән кисешкәнгә кадәр уза, алга таба көньякка таба Җиңү проспектының күчәр сызыгы буйлап Казан шәһәре Совет һәм Идел буе районнарының административ чиге белән кисешкәнгә кадәр бара, алга таба көнбатыш юнәлештә Казан шәһәре Совет һәм Идел буе районнарының административ чиге буйлап Даурия урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр бара, алга таба көнчыгышка таба Даурия урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, 2 нче Даурия урамына кадәр уза, аннары уңга борыла һәм 2 нче Даурия урамының күчәр

сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Латыш Укчылары урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Латыш Укчылары урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Карбышев урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары төньякка таба Карбышев урамының күчәр сызыгы буйлап Даурия урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза.

## 9 нчы суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районы буенча җәмәгать судьясының 9 нчы суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Даурия һәм Карбышев урамнарының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнчыгышка таба Даурия урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Гадел Кутуй урамының икенче дәрәҗәдәге юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Гадел Кутуй урамының икенче дәрәҗәдәге автомобиль юлы буйлап, сул якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, 86 нчы йортның 2 нче корпусының көньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә автомобиль юлы буйлап Бохара урамына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Бохара урамының күчәр сызыгы буйлап Родина урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба Родина һәм Бохара урамнарының күчәр сызыклары буйлап Гадел Кутуй урамына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Гадел Кутуй урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Достоевский урамында урнашкан Мәскәү – Пермь тимер юлы өстендәге автомобиль күпере буенча уза торган Казан шәһәре Совет һәм Вахитов районнарының административ чиге белән кисешү ноктасына кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньяк юнәлештә Казан шәһәре Совет һәм Вахитов районнарының, аннары Казан шәһәре Идел буе районының административ чиге буйлап Даурия урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза, алга таба көнчыгышка таба Даурия урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, 2 нче Даурия урамына кадәр уза, аннары уңга борыла һәм 2 нче Даурия урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Латыш Укчылары урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Латыш

Укчылары урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Карбышев урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары төньякка таба Карбышев урамының күчәр сызыгы буйлап Даурия урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза.

## 10 нчы суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районы буенча җәмәгать судьясының 10 нчы суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Минск һәм Юлиус Фучик урамнарының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньякка таба Юлиус Фучик урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, 106А йортның көньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм автомобиль юлы буенча көнчыгышка таба, Юлиус Фучик урамындагы 106А, 98, 102 нче һәм Нокса Авышлыгы урамындагы 13 нче йортларны кертеп, Нокса Авышлыгы урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көньяк-көнбатышка таба Нокса Авышлыгы урамының күчәр сызыгы буйлап Юлиус Фучик урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньякка таба Юлиус Фучик урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Академик Завойский урамының күчәр сызыгы буйлап уза торган Казан шәһәре Совет һәм Идел буе районнарының административ чигенә кадәр уза, алга таба көнчыгышка таба Казан шәһәре Совет һәм Идел буе районнарының административ чиге буйлап, Вознесенское һәм Привольный торак пунктлары территорияләрен кертеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Питрәч муниципаль районы белән чигенә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм төньяк юнәлештә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге буенча Мамадыш тракты белән кисешү ноктасына кадәр бара, алга таба көньякка таба Мамадыш трактының күчәр сызыгы буйлап Самосырово зираты коймасының төньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм Самосырово зираты коймасының көнчыгыш һәм көньяк яклары буйлап уза, алга таба көнбатыш юнәлештә Самосырово торак пунктының көньяк кырые буйлап, сул якта урнашкан территорияне кертеп, Нокса елгасына кадәр уза, аннары көньякка таба Нокса елгасы үзәне буенча (агым буенча өскә таба) Зур Клы-

ки торак пункты буйлап, уң ярны кертеп, Вознесенское торак пункты кырыена кадәр уза, алга таба көнбатышка таба, Вознесенское торак пункты территориясен кертеп, урман утыртмалары чиге буенча бара, Минск урамындагы 37 нче йортның көнбатыш ягыннан әлеге урамга килеп чыга, аннары шул ук юнәлештә Минск урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Юлиус Фучик урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза.

## 11 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районы буенча җәмәгать судьясының 11 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Искра һәм Николай Ершов урамнарының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньяк юнәлештә Искра урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Патрис Лумумба урамына кадәр уза, аны кисеп үтә һәм алга таба шул ук юнәлештә Шуртыгин урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Курск урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм Курск урамының күчәр сызыгы буйлап Гвардия урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньякка таба Гвардия урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Гадел Кутуй урамының күчәр сызыгы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көнбатышка таба Гадел Кутуй урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Достоевский урамында урнашкан Мәскәү – Пермь тимер юлы өстендәге автомобиль юлы күпере буенча уза торган Казан шәһәре Совет һәм Вахитов районнарының административ чигенә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм төньякка таба Казан шәһәре Совет һәм Вахитов районнарының, аннары Казан шәһәре Яңа Савин районының административ чиге буйлап Ямашев проспектында урнашкан автомобиль күперенә кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Ямашев проспектының күчәр сызыгы буйлап Академик Арбузов урамы һәм Себер трактының күчәр сызыклары кисешү ноктасына кадәр бара, алга таба көньякка таба Себер трактының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, 8 Март урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары көнчыгышка таба 8 Март урамының күчәр сызыгы буйлап Журналистлар урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба

көньякка таба Журналистлар урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Академик Губкин урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Академик Губкин урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Совет мәйданына кадәр бара, аннары Совет мәйданын көнчыгыш һәм көньяк якларыннан Николай Ершов урамының күчәр сызыгы белән кисешкән урынга кадәр әйләнеп үтә, алга таба көньякка таба Николай Ершов урамының күчәр сызыгы буйлап Искра урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза.

### 12 нче суд участогы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Совет районы буенча җәмәгать судьясының 12 нче суд участогы чигенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Совет мәйданының көнчыгыш ягында урнашкан Академик Губкин һәм Космонавтлар урамнарының күчәр сызыклары кисешкән урында урнашкан ноктадан алып төньяк-көнчыгышка таба Академик Губкин урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Журналистлар урамына кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Журналистлар урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, 8 Март урамына кадәр уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 8 Март урамының күчәр сызыгы буйлап Себер тракты белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары төньякка таба Себер трактының күчәр сызыгы буйлап Нокса елгасы аша автомобиль күперендә урнашкан ноктага кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көньякка таба Нокса елгасы үзәне буенча (агым буенча өскә таба), сул ярны кертеп, Зирекле урамында урнашкан автомобиль күперенә кадәр уза, алга таба уңга борыла һәм көньяк-көнчыгышка таба Дорожный тыкрыгының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Җиңү проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньякка таба Җиңү проспектының күчәр сызыгы буйлап Аграр урамы һәм Мамадыш трактының күчәр сызыклары кисешкән ноктага кадәр уза, аннары төньяк-көнбатышка таба Аграр һәм Космонавтлар урамнарының күчәр сызыклары буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Совет мәйданының көнчыгыш ягында урнашкан Академик Губкин урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 17 апреле
№ 32-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 569. «Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» 2011 елның 1 августындагы 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8 (I өлеш), кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы
Чаллы шәһәре буенча Татарстан
Республикасы җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

## Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы

### 1 нче суд участогы

1 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Татарстан урамы һәм Сөембикә проспектының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба Татарстан урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Шамил Усманов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Шамил Усманов урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Йорт төзүчеләр бульвары белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба Йорт төзүчеләр бульварының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Чулман проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Чулман проспектының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан гаражларны һәм ягулык салу станциясен кертеп, Яр буе һәм Татарстан урамнары белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көнбатыш юнәлештә Яр буе урамының күчәр сызыгы буйлап, Боровецкое торак пункты территориясе буенча аның кырыена кадәр бара, аннары уңга борыла һәм Боровецкое торак пунктының көньяк-көнбатыш кырые буйлап уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба туры сызык буенча Шилнә елгасы тамагында урнашкан «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чигенә кадәр бара, алга таба көнбатышка таба «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап, Түбән Кама сусаклагычы култыгы акваториясе буенча (сусаклагычның сул ярының яр сызыгы буенча) Түбән Кама сусаклагычының сул ярының яр сызыгында Автозавод һәм Чулман проспектлары киселешендә урнашкан ноктага перпендикуляр урнашкан ноктага кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньяк-көнчыгышка таба туры сызык буенча яр буйлап уза, алга таба «Яр буе» шәһәр урман паркы аша аның

кырыена кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә грунт юл буйлап, автомобильләр куеп тору урынының төньяк-көнчыгыш чиге кыриеннан, Яңа шәһәрнең 61 нче микрорайоны территориясен кертеп, Автозавод һәм Чулман проспектларының күчәр сызыклары кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба Автозавод проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Тынычлык проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Тынычлык проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Йорт төзүчеләр һәм Яшь Ленинчылар бульварлары белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба сулга борыла һәм төньяк-көнбатышка таба Йорт төзүчеләр бульвары буенча уза торган автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Сөембикә проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Сөембикә проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Татарстан урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

1 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең көньяк-көнчыгыш өлешендәге сәнәгать-коммуналь зона территориясендә урнашкан басу аша кишәрлек керә, аның чиге Техника һәм Металлург урамнарының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба Техника урамының күчәр сызыгы буйлап, уң якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, Шилнә елгасы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба Шилнә елгасы үзәне буенча Мотор урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Мотор урамының күчәр сызыгы буйлап Металлург урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба Металлург урамының күчәр сызыгы буйлап Иске Гәрдәле авылының көнбатыш чиге буенча узучы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чигенә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көньяк-көнбатышка таба «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап, Тогай карьеры территориясен кертеп, Чаллы – Минзәлә автомобиль юлының (М-7 федераль трассасы) көньяк-көнбатыш ягы белән икенче җылылык чыганагының көньяк-көнчыгыш чиге киселешендә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Чаллы – Минзәлә автомобиль юлының (М-7 федераль трассасы) күчәр сызыгы буйлап Металлург урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Металлург

урамының күчәр сызыгы буйлап Техника урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 2 нче суд участогы

2 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Шамил Усманов урамы һәм Яшьлек проспектының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнбатышка таба Шамил Усманов урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Йорт төзүчеләр бульвары белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Йорт төзүчеләр бульварының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Чулман проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Чулман проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Яр буе һәм Татарстан урамнары белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көнбатыш юнәлештә Яр буе урамының күчәр сызыгы буйлап, уң якта урнашкан Боровецкое торак пункты территориясен кертеп, аның кырыена кадәр уза, аннары уңга борыла һәм Боровецкое торак пунктының көньяк-көнбатыш кырые буйлап аның көньяк почмагына кадәр бара, алга таба туры сызык буенча Шилнә елгасы тамагында урнашкан «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чигенә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең көнчыгыш чигендә урнашкан Сәгыйть Хәлфин һәм Нурми Шәрипов урамнарының күчәр сызыклары кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба Сәгыйть Хәлфин урамының күчәр сызыгы буйлап, уң якта урнашкан Яңа шәһәрнең 71 нче микрорайоны территориясен кертеп, Урман аръягы проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньякка таба Урман аръягы проспектының күчәр сызыгы буйлап, Яңа шәһәрнең 67 нче микрорайоны территориясен кертеп, Абдулла Алиш урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Абдулла Алиш урамының күчәр сызыгы буйлап, Яңа шәһәрнең 66 нчы микрорайоны торак массивы территориясен кертеп, Яшьлек проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнбатышка таба Яшьлек проспектының күчәр сызыгы буйлап Шамил Усманов урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

2 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең көньяк-көнчыгыш өлешендәге сәнәгать-коммуналь зона территориясендә урнашкан басу аша кишәрлек керә, аның чиге 5 нче автомобиль юлының һәм Мотор урамының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнбатышка таба 5 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, уң якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, 52 нче автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба 52 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Машина төзүчеләр урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба Машина төзүчеләр урамының күчәр сызыгы буенча Мотор урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка борыла һәм Мотор урамының күчәр сызыгы буйлап 5 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 3 нче суд участогы

3 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Вахитов исемендәге һәм Сөембикә проспектларының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба Вахитов исемендәге проспектның күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Шамил Усманов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Шамил Усманов урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Шамил Усманов урамындагы 85 нче йортның көньяк-көнчыгыш почмагы янындагы Җиңүнең 60 еллыгы урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнбатышка таба Җиңүнең 60 еллыгы урамының күчәр сызыгы буйлап, уң якта урнашкан Яңа шәһәрнең 44 нче микрорайоны торак массивының бер өлешен кертеп, Чулман проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Чулман проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Чулман проспекты буенча 73 нче йортның (Никахлашу сарае) көньяк почмагыннан 150 метрда урнашкан, «Яр буе» шәһәр урман паркы аша уза торган автомобиль юлы белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм төньяк юнәлештә әлеге автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, уң якта урнашкан Никахлашу сарае территориясен һәм «Яр буе» шәһәр

урман паркы территориясенең бер өлешен кертеп, Түбән Кама сусаклагычының сул ярында урнашкан көймә станциясенә кадәр бара, алга таба көймә станциясенең көнчыгыш чиге буйлап яр буе полосасына кадәр төньякка таба бара, алга таба шул ук юнәлештә Түбән Кама сусаклагычы култыгы акваториясе буенча Түбән Кама сусаклагычы акваториясе аша узучы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чигенә кадәр уза, аннары көнчыгыш юнәлештә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап (Түбән Кама сусаклагычының сул ярының яр сызыгы буенча) Түбән Кама сусаклагычының сул ярының яр сызыгында Автозавод һәм Чулман проспектлары киселешендә урнашкан ноктага перпендикуляр урнашкан ноктага кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көньяк-көнчыгышка таба яр буйлап туры сызык буенча, аннары «Яр буе» шәһәр урман паркы аша аның кырыена кадәр бара, алга таба шул ук юнәлештә грунт юл буйлап Яңа шәһәрнең 61 нче микрорайоны территориясе кырыеннан, уң якта урнашкан ипподром территориясен кертеп, автомобильләр куеп тору урынының төньяк почмагына кадәр бара, алга таба автомобильләр куеп тору урынының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, автомобильләр куеп тору урыны территориясен кертеп, Автозавод һәм Чулман проспектлары киселешендәге ноктага кадәр уза, алга таба Автозавод проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Сөембикә проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көньяк-көнбатышка таба Сөембикә проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Вахитов исемендәге проспектның күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

3 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең көньяк-көнчыгыш өлешендәге сәнәгать-коммуналь зона территориясендә урнашкан басу аша кишәрлек керә, аның чиге тимер юллар һәм 50 нче автомобиль юлы киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнчыгышка таба тимер юллар буенча, сул якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, Мотор урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Мотор урамының күчәр сызыгы буйлап 5 нче автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба 5 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап 50 нче автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көньяк-көнчыгышка таба 50 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап тимер юллар белән кисешкән җиргә кадәр уза.

## 4 нче суд участогы

4 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Сөембикә һәм Рәис Беляев проспектларының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнчыгышка таба Сөембикә проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Хәсән Туфан проспекты буенча 29А йортының көньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнчыгыш юнәлештә Хәсән Туфан проспекты буенча 29, 31, 33 һәм 43 нче йортларның көньяк-көнбатыш кырыеннан уза торган автомобиль юлы буйлап, әлеге йортларны кертеп, Шамил Усманов урамының күчәр сызыгы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба аның күчәр сызыгы буйлап Хәсән Туфан проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Хәсән Туфан проспектының күчәр сызыгы буйлап Хәсән Туфан проспекты буенча 26 нчы йортның көньяк-көнбатыш почмагы каршында автомобиль транспорты борылыш ясый торган урында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары сулга борыла һәм туры юнәлештә автомобиль юлы буенча әлеге почмакка кадәр һәм алга таба шул ук юнәлештә Хәсән Туфан проспекты буенча 30 нчы йортның көнбатыш кырыеннан аның төньяк-көнбатыш почмагына кадәр уза, алга таба уңга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә Сөембикә проспекты буенча 37 нче һәм 39 нчы йортларның көньяк кырыеннан, Хәсән Туфан проспекты буенча 30 нчы, 26 нчы һәм Сөембикә проспекты буенча 35 нче йортларны кертеп, Сөембикә проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба аның күчәр сызыгы буйлап көньяк юнәлештә Хәсән Туфан проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба Хәсән Туфан проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Мәскәү проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба Мәскәү проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Мәскәү проспекты буенча 105 нче йортның көньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба төньяк юнәлештә автомобиль юлы буенча уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Николай Ершов урамының күчәр сызыгы буйлап, Яңа шәһәрнең 4 нче микрорайоны территориясен кертеп, Тынычлык проспекты буенча 38 нче йортның көнчыгыш почмагы янында урнашкан нокта-

га кадәр уза, аннары сулга борыла һәм автомобиль юлы буйлап Тынычлык проспекты буенча 38 нче йортның көньяк-көнчыгыш ягы буйлап, әлеге йортны кертеп, Рәис Беляев проспекты буенча 12 нче йортка кадәр бара, алга таба уңга борыла һәм төньяк-көнбатышка таба Тынычлык проспекты буенча 38 нче йортның көньяк-көнчыгыш кырыеннан Тынычлык проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Тынычлык проспектының күчәр сызыгы буенча Рәис Беляев проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Рәис Беляев проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Сөембикә проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

4 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең көньяк-көнчыгыш өлешендәге сәнәгать-коммуналь зона территориясендә урнашкан басу аша кишәрлек керә, аның чиге Сәнәгать урамының һәм 42 нче автомобиль юлының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнчыгышка таба Сәнәгать урамының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, Мотор урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Мотор урамының күчәр сызыгы буйлап тимер юллар белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көнбатыш юнәлештә тимер юллар буйлап 48 нче автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба 48 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап 63 нче автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба 63 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап 42 нче автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көньяк-көнчыгышка таба 42 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Сәнәгать урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

## 5 нче суд участогы

5нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Хәсән Туфан проспектының һәм Машина төзүчеләр урамының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба Хәсән Туфан проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Энтузиастлар

бульварына кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Энтузиастлар бульвары буенча уза торган автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Академик Рубаненко урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба Академик Рубаненко урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Тынычлык проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба Тынычлык проспектының күчәр сызыгы буйлап Вахитов исемендәге проспект белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Вахитов исемендәге проспектның күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Мәскәү проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Мәскәү проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Автозавод проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Автозавод проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Машина төзүчеләр урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көньяк-көнчыгышка таба Машина төзүчеләр урамының күчәр сызыгы буйлап Хәсән Туфан проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

5 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең көньяк-көнчыгыш өлешендәге сәнәгать-коммуналь зона территориясендә урнашкан басу аша кишәрлек керә, аның чиге 48 нче һәм 5 нче автомобиль юлларының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба 48 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, тимер юллар белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә тимер юллар буйлап 50 нче автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба 50 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап 5 нче автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба 5 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап 48 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 6 нчы суд участогы

6 нчы суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Гидротөзүчеләр урамының һәм Муса Җәлил исемендәге проспектның күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба Гидротөзүчеләр урамының күчәр сызыгы буйлап Гидротөзүчеләр урамы буенча 1 нче йортның төньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм автомобиль юлы буйлап Гидротөзүчеләр урамы буенча 1 нче һәм Парк тыкрыгы буенча 2 нче йортларның төньяк-көнбатыш кырыеннан, Гидротөзүчеләр урамы буенча 3 нче һәм Парк тыкрыгы буенча 4 нче йортларны кертеп, Парк тыкрыгы буенча 4 нче йортның көньяк почмагына кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба Парк тыкрыгы буенча 1 нче йортның төньяк-көнчыгыш кырыеннан, Парк тыкрыгы буенча 6 нчы һәм 8 нче йортларны кертеп, Парк тыкрыгы буенча 8 нче йортның көнбатыш почмагына кадәр уза, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба Гидротөзүчеләр урамы буенча 5 нче йортның көньяк-көнчыгыш кырыеннан Гидротөзүчеләр урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Гидротөзүчеләр урамы буенча, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Шлюз урамына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Шлюз урамының күчәр сызыгы буйлап 150 метр, уң якта урнашкан гаражларны кертеп, Түбән Кама сусаклагычының сул ярына кадәр уза, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба Түбән Кама сусаклагычының сул ярындагы яр буе полосасы буенча, сул ярны кертеп, Мәләкәс елгасы тамагына кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Мәләкәс елгасы үзәне буенча агым уңаена өскә таба, сул ярны кертеп, Яр Чаллы проспекты буенча урнашкан автомобиль юлы күперенә кадәр уза, алга таба көнбатышка таба Яр Чаллы һәм Муса Җәлил исемендәге проспектларның күчәр сызыклары буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Гидротөзүчеләр урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 7 нче суд участогы

7 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Тынычлык һәм Автозавод проспектларының күчәр сызыклары

киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнчыгышка таба Тынычлык проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Йорт төзүчеләр һәм Яшь Ленинчылар бульварлары белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм Яшь Ленинчылар бульварының күчәр сызыгы буйлап көньяк-көнчыгышка таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Мәскәү проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба Мәскәү проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Галиәсгар Камал исемендәге бульвар белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көньяк-көнчыгышка таба Галиәсгар Камал исемендәге бульварның күчәр сызыгы буйлап, уң якта урнашкан йортларны кертеп, Җиңүнең 40 еллыгы урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба Җиңүнең 40 еллыгы урамының күчәр сызыгы буйлап Автозавод проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Автозавод проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Мәскәү проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Мәскәү проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Мәскәү проспекты буенча 165А йортның көньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм Яңа шәһәрнең 29 нчы һәм 30 нчы микрорайоннары йортлары арасыннан, 29 нчы микрорайон территориясен кертеп, Шишкин бульвары буенча уза торган автомобиль юлы буйлап Шишкин бульвары буенча 5 нче йортның төньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба автомобиль юлы буенча Шишкин проезды белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Шишкин проездының күчәр сызыгы буенча Яңа шәһәрнең 28 нче микрорайоны йортлары буйлап, 29 нчы микрорайон йортларын кертеп, Автозавод проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Автозавод проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Тынычлык проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

7 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең көньяк-көнчыгыш өлешендәге сәнәгать-коммуналь зона территориясендә урнашкан басу аша кишәрлек керә, аның чиге Техника һәм Сәнәгать урамнарының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба Техника урамының күчәр сызыгы буйлап, уң

якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, Машина төзүчеләр урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Машина төзүчеләр урамының күчәр сызыгы буйлап Автомобиль җыю проезды белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Автомобиль җыю проездының күчәр сызыгы буйлап 5 нче автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба 5 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап 48 нче автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба 48 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап 63 нче автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба 63 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап 42 нче автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба 42 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Сәнәгать урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көньяк-көнбатышка таба Сәнәгать урамының күчәр сызыгы буйлап Техника урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

## 8 нче суд участогы

8 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Тынычлык, Яшьлек проспектлары һәм Абдулла Алиш урамының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнбатышка таба Тынычлык проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Йорт төзүчеләр һәм Яшь Ленинчылар бульварлары белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Яшь Ленинчылар бульварының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Мәскәү проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба Мәскәү проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Галиәсгар Камал исемендәге бульвар белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көньяк-көнчыгышка таба Галиәсгар Камал исемендәге бульварның күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан йортларны кертеп, Җиңүнең 40 еллыгы урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба Җиңүнең 40 еллыгы урамының күчәр сызыгы буйлап Автозавод проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба

Автозавод проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Сәнәгать урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Сәнәгать урамының күчәр сызыгы буйлап Яшьлек проспекты һәм Мотор урамы белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм Мотор урамының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, Металлург урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба Металлург урамының күчәр сызыгы буйлап Иске Гәрдәле авылының көнбатыш чиге буйлап узучы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең көнчыгыш чигенә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм төньяк юнәлештә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап Сәгыйть Хәлфин һәм Нурми Шәрипов урамнары киселешендә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Сәгыйть Хәлфин урамының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан территорияне кертеп, Урман аръягы проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньякка таба Урман аръягы проспектының күчәр сызыгы буйлап Абдулла Алиш урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көньяк-көнбатышка таба Абдулла Алиш урамының күчәр сызыгы буйлап, Яңа шәһәрнең 64 нче һәм 65 нче микрорайоннары территорияләрен кертеп, Тынычлык, Яшьлек проспектларының һәм Абдулла Алиш урамының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктага кадәр бара.

## 9 нчы суд участогы

9 нчы суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Маршал Жуков исемендәге һәм Низаметдинов Р.М. исемендәге урамнарның күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнбатышка таба Маршал Жуков исемендәге урамның күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Комаров исемендәге урам белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Комаров исемендәге урамның күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Һади Такташ исемендәге урам белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба Һади Такташ исемендәге урамның күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Һади Такташ исемендәге урам буенча 14А йортның көнбатыш почмагы янында урнашкан нокта-

га кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә автомобиль юлы буенча Һади Такташ исемендәге урам буенча 8 нче, Аркылы урамы буенча 19, 17, 13, 11 нче һәм Таң урамы буенча 213 нче йортларның төньяк кырыеннан, Һади Такташ исемендәге урамдагы 14А, 8 нче һәм Аркылы урамы буенча 21, 3В, 3, 3А йортларын кертеп, Таң урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Таң урамының күчәр сызыгы буенча Аркылы урамының күчәр сызыгы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба Аркылы урамының күчәр сызыгы буйлап Казан проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Казан проспектының күчәр сызыгы буйлап, Рябинушка торак пункты территориясен кертеп, Мәләкәс елгасы аша автомобиль юлы күпере уртасында урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатыш юнәлештә Чаллы елгасы үзәне буенча агым буйлап аска таба, сул ярны кертеп, Яр Чаллы проспекты белән кисешкән урында урнашкан автомобиль юлы күперенә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Яр Чаллы проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Низаметдинов Р.М. исемендәге урам белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көньяк-көнчыгышка таба Низаметдинов Р.М. исемендәге урамның күчәр сызыгы буйлап Маршал Жуков исемендәге урамның күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 10 нчы суд участогы

10 нчы суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Энергетиклар тыкрыгы һәм Муса Җәлил исемендәге проспектның күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Энергетиклар тыкрыгының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Габдулла Тукай исемендәге яр буендагы 23 нче йортның көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә, шушы йортны кертеп, йортның көньяк-көнбатыш ягыннан бара, аннары Габдулла Тукай исемендәге яр буен кисеп үтә, Габдулла Тукай исемендәге яр буендагы 14 нче йортның төньяк-көнчыгыш ягы буенча Мәләкәс елгасының сул ярына кадәр уза, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба Мәләкәс елгасы үзәне буенча агым буйлап аска таба, сул ярны кертеп, Габ-

дулла Тукай исемендәге яр буендагы 93/100 нче йортның көньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм туры сызык буйлап төньяк-көнбатышка таба Габдулла Тукай исемендәге яр буе белән кисешкән җиргә кадәр уза, аны кисеп үтә һәм шул ук юнәлештә автомобиль юлы буенча Габдулла Тукай исемендәге яр буендагы 93/100 нче һәм Муса Җәлил исемендәге проспект буенча 96 нчы йортларның көньяк-көнбатыш кырыеннан, Габдулла Тукай исемендәге яр буендагы 83, 91, 89 нчы һәм Муса Җәлил исемендәге проспект буенча 92 нче, 88 нче йортларны кертеп, Муса Җәлил исемендәге проспектның күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба Муса Җәлил исемендәге проспектның күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Энергетиклар тыкрыгының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

## 11 нче суд участогы

11 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Рәис Беляев һәм Сөембикә проспектларының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба Рәис Беляев проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Раскольников урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, Рәис Беляев проспектының күчәр сызыгын дәвам итеп, шул ук юнәлештә автомобиль юлы күчәр сызыгы буенча, Раскольников урамы буенча 60 нчы йортны кертеп, Кама елгасы (Түбән Кама сусаклагычы) ярында урнашкан шәһәр пляжы территориясенә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм шәһәр пляжының көнчыгыш ягы буйлап «Сан Дали» пляжының көньяк чигенә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көнбатыш юнәлештә «Сан Дали» пляжының көньяк чиге буйлап яр полосасына кадәр бара, алга таба туптуры төньяк-көнбатышка таба Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, очлаеп кергән коры җирне һәм утрауны кертеп, Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап уза торган «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чигенә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгыш юнәлештә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап (Түбән Кама сусаклагычының сул ярының яр сызыгы буйлап) Түбән Кама сусаклагычының сул ярының яр сызыгы һәм көймә станциясенең көнчыгыш чиге кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара, аннары уңга

борыла һәм көньякка таба көймә станциясенең көнчыгыш чиге буйлап автомобиль юлына кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап «Яр буе» урман паркы аркылы, уң якта урнашкан урман паркы территориясен кертеп, Чулман проспекты буенча 73 нче йортның (Никахлашу сарае) көньяк почмагыннан 150 метр ераклыкта Чулман проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба Чулман проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Пушкин урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Пушкин урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Шамил Усманов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Шамил Усманов урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Шамил Усманов урамы буенча 48 нче йортның төньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньяк-көнчыгыш юнәлештә Хәсән Туфан проспекты буенча 29, 31, 33 һәм 43 нче йортларның көньяк-көнбатыш кырыеннан уза торган автомобиль юлы буенча, Шамил Усманов урамы буенча 48 нче, Хәсән Туфан проспекты буенча 41 нче һәм Сөембикә проспекты буенча 31 нче, 33 нче йортларны кертеп, Сөембикә проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Сөембикә проспектының күчәр сызыгы буйлап Рәис Беляев проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

## 12 нче суд участогы

12 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Сөембикә һәм Автозавод проспектларының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнбатышка таба Сөембикә проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Вахитов исемендәге проспект белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Вахитов исемендәге проспектның күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Мәскәү проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Мәскәү проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Мәскәү проспектындагы 165А йортның көньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары

сулга борыла һәм Яңа шәһәрнең 29 нчы һәм 30 нчы микрорайоннары йортлары арасыннан Шишкин бульвары буенча уза торган автомобиль юлы буйлап, 30 нчы микрорайон территориясен кертеп, Шишкин бульвары буенча 5 нче йортның төньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба автомобиль юлы буенча Шишкин проезды белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Шишкин проездының күчәр сызыгы буйлап Яңа шәһәрнең 29 нчы микрорайоны йортлары кырыеннан, Яңа шәһәрнең 28 нче микрорайоны территориясен кертеп, Автозавод проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Автозавод проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Сөембикә проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

## 13 нче суд участогы

13 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Сөембикә һәм Вахитов исемендәге проспектларның күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Вахитов исемендәге проспектның күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Тынычлык проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Тынычлык проспектының күчәр сызыгы буйлап Академик Рубаненко урамына кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Академик Рубаненко урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Энтузиастлар бульвары белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба Энтузиастлар бульвары буенча уза торган автомобиль юлының күчәр сызыгы буенча, так якта урнашкан йортларны кертеп, Хәсән Туфан проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Хәсән Туфан проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Сөембикә проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба Сөембикә проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Вахитов исемендәге проспектның күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

13 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең көньяк-көнчыгыш өлешендәге сәнәгать-

коммуналь зона территориясендә урнашкан басу аша кишәрлек керә, аның чиге Сәнәгать һәм Техника урамнарының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнчыгышка таба Сәнәгать урамының күчәр сызыгы буйлап, уң якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, Мотор урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Мотор урамының күчәр сызыгы буйлап Шилнә елгасы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көньяк-көнбатыш юнәлештә Шилнә елгасы үзәне буйлап Техника урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Техника урамының күчәр сызыгы буйлап Сәнәгать урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 14 нче суд участогы

14 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Маршал Жуков исемендәге һәм Комаров исемендәге урамнарның күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнбатышка таба Комаров исемендәге урамның күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Һади Такташ исемендәге урам белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Һади Такташ исемендәге урамның күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Һади Такташ исемендәге урам буенча 14А йортның көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә автомобиль юлы буйлап Һади Такташ исемендәге урам буенча 14А, 18 нче, Аркылы урамы буенча 21, 3В, 3, 3А йортларның көньяк кырыеннан, Һади Такташ исемендәге урам буенча 8 нче, Аркылы урамы буенча 19, 17, 13, 11 нче һәм Таң урамы буенча 213 нче йортларны кертеп, Таң урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Таң урамының күчәр сызыгы буйлап Аркылы урамының күчәр сызыгы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба Аркылы урамының күчәр сызыгы буйлап Казан проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Казан проспектының күчәр сызыгы буйлап, уң якта урнашкан сәнәгать зонасы территориясен кертеп, Чаллы елгасы аркылы автомобиль юлы күпере уртасында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көньяк юнәлештә, сул ярны кертеп, Чал-

лы елгасы үзәне буйлап агым буенча өскә таба «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чигенә кадәр уза, алга таба көнбатыш юнәлештә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап Магистраль урамы белән сәнәгать билгеләнешендәге тимер юллар киселешендә “Чаллы шәһәре” муниципаль берәмлегенең көньяк-көнбатыш чигендә урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба сәнәгать билгеләнешендәге тимер юлга бүлеп бирелгән полосаның төньягы буйлап, уң якта урнашкан төзелеш индустриясе сәнәгать зонасы базасы территориясен кертеп, Суар торак пунктының көньяк-көнчыгыш читенә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм төньякка таба грунт автомобиль юлы буенча «Лада-2» гараж-төзелеш кооперативының көньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба «Лада-2» гараж-төзелеш кооперативы һәм Казан проспекты, 3/1 нче йорт адресы буенча урнашкан 132 нче ягулык салу станциясе территорияләре арасыннан, 132 нче ягулык салу станциясе территориясен кертеп, Казан проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Казан проспектының күчәр сызыгы буйлап, уң якта урнашкан территорияне кертеп, Мәләкәс елгасы аркылы автомобиль юлы күпере уртасында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба Мәләкәс елгасы үзәне буйлап агым буенча аска таба, уң ярда урнашкан Кызыл Чаллы һәм Мәләкәс арты торак пунктлары территорияләрен кертеп, Яр Чаллы проспекты буенча урнашкан автомобиль юлы күперенә кадәр бара, алга таба көнчыгышка таба Яр Чаллы проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Сарман трактына кадәр уза, алга таба көньякка таба Сарман трактының күчәр сызыгы буйлап Маршал Жуков исемендәге урамга кадәр уза, аннары Маршал Жуков исемендәге урамга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба аның күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Комаров исемендәге урамның күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 15 нче суд участогы

15 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Хәсән Туфан проспекты һәм Шамил Усманов урамының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Хәсән Туфан проспектының күчәр сызыгы

буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Хәсән Туфан проспекты буенча 26 нчы йорт почмагы каршында автомобиль транспорты борылыш ясый торган урында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм туры юнәлештә автомобиль юлы буенча әлеге йортның көньяк-көнбатыш почмагына кадәр һәм алга таба шул ук юнәлештә, Хәсән Туфан проспекты буенча 32 нче йортны кертеп, Хәсән Туфан проспекты буенча 30 нчы йортның көнбатыш кырыеннан аның төньяк-көнбатыш почмагына кадәр уза, алга таба уңга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә Хәсән Туфан проспекты буенча 30 нчы, 26 нчы һәм Сөембикә проспекты буенча 35 нче йортларның төньяк-көнчыгыш кырыеннан, Сөембикә проспекты буенча 37 нче һәм 39 нчы йортларны кертеп, Сөембикә проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба Сөембикә проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Вахитов исемендәге проспект белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба Вахитов исемендәге проспектның күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Шамил Усманов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Шамил Усманов урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Шамил Усманов урамы буенча 85 нче йортның көньяк-көнчыгыш почмагы янындагы Җиңүнең 60 еллыгы урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнбатышка таба Җиңүнең 60 еллыгы урамының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан Яңа шәһәрнең 44 нче микрорайоны торак массивының бер өлешен кертеп, Чулман проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Чулман проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Пушкин урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Пушкин урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Шамил Усманов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Шамил Усманов урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Хәсән Туфан проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньяк-көнчыгышка таба Хәсән Туфан проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Сөембикә проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

15 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең көньяк-көнчыгыш өлешендәге сәнәгать-коммуналь зона территориясендә урнашкан басу аша кишәрлек керә, аның чиге Автомобиль җыю проезды һәм Машина төзүчеләр урамының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Автомобиль җыю проездының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, 5 нче автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба 5 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап 52 нче автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба 52 нче автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Машина төзүчеләр урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көньяк-көнбатышка таба Машина төзүчеләр урамының күчәр сызыгы буйлап Автомобиль җыю проездының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 16 нчы суд участогы

16 нчы суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Тынычлык, Яшьлек проспектлары һәм Абдулла Алиш урамының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнбатышка таба Тынычлык проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Йорт төзүчеләр һәм Яшь Ленинчылар бульварлары белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнбатышка таба Йорт төзүчеләр бульварындагы икенче дәрәҗә автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, уң якта урнашкан Яңа шәһәрнең 22 нче микрорайоны территориясенең бер өлешен һәм Яңа шәһәрнең 24 нче микрорайоны территориясен кертеп, Сөембикә проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Сөембикә проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Татарстан урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Татарстан урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Шамил Усманов урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Шамил Усманов урамының күчәр сызыгы

буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Яшьлек проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көньяк-көнчыгышка таба Яшьлек проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Тынычлык проспекты һәм Абдулла Алиш урамының күчәр сызыклары белән кисешкән ноктага кадәр уза.

16 нчы суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең көньяк-көнчыгыш өлешендәге сәнәгать-коммуналь зона территориясендә урнашкан басу аша кишәрлек керә, аның чиге Машина төзүчеләр урамы һәм Минзәлә трактының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнчыгышка таба Машина төзүчеләр урамының күчәр сызыгы буйлап, уң якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, Техника урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Техника урамының күчәр сызыгы буйлап Транспорт проезды белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба Транспорт һәм Хлебный проездларының күчәр сызыклары буйлап Минзәлә тракты белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнбатышка таба Минзәлә трактының күчәр сызыгы буйлап Машина төзүчеләр урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 17 нче суд участогы

17 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Тынычлык һәм Халыклар Дуслыгы проспектларының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Халыклар Дуслыгы проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Машина төзүчеләр урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Машина төзүчеләр урамының күчәр сызыгы буйлап Хәсән Туфан проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба Хәсән Туфан проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Мәскәү проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Мәскәү проспектының күчәр сызыгы буйлап, «Гренада» паркы территориясен кертеп, Мәскәү проспекты буенча 105 нче йортның көньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба төньяк юнәлештә автомобиль юлы буйлап, Яңа шәһәрнең 5 нче мик-

рорайоны территориясен кертеп, Тынычлык проспекты буенча 38 нче йортның көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм автомобиль юлы буйлап Тынычлык проспекты буенча 38 нче йортның көньяк-көнчыгыш кырыеннан, Төзүчеләр бульвары буенча 1 нче йортны кертеп, Рәис Беляев проспекты буенча 12 нче йортка кадәр бара, алга таба уңга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба Тынычлык проспекты буенча 38 нче йортның көньяк-көнбатыш кырыеннан Тынычлык проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба Тынычлык проспектының күчәр сызыгы буйлап Халыклар Дуслыгы проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

17 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең көньяк-көнчыгыш өлешендәге сәнәгать-коммуналь зона территориясендә урнашкан басу аша кишәрлек керә, аның чиге ТЭЦ проезды һәм Металлург урамының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба ТЭЦ проездының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, Сәнәгать урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Сәнәгать урамының күчәр сызыгы буйлап Минзәлә тракты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Минзәлә трактының күчәр сызыгы буйлап Металлург урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба Металлург урамының күчәр сызыгы буйлап ТЭЦ проездының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 18 нче суд участогы

18 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Рәис Беляев һәм Сөембикә проспектларының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба Рәис Беляев проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Шамил Усманов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Шамил Усманов урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Халыклар Дуслыгы проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба Халыклар Дуслыгы проспектының күчәр сызыгы буйлап, так

якта урнашкан йортларны кертеп, Раскольников урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Раскольников урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Раскольников урамы буенча 29 нчы йортның көньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньяк-көнчыгышка таба Яңа шәһәрнең 37 нче һәм 36 нчы микрорайоннары йортлары арасындагы автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, 37 нче микрорайон территориясен кертеп, Академик Королев урамы һәм Чулман проспектының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә Академик Королев урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Шамил Усманов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Шамил Усманов урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Халыклар Дуслыгы проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Халыклар Дуслыгы проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Сөембикә проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба Сөембикә проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Рәис Беляев проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 19 нчы суд участогы

19 нчы суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Яр Чаллы проспекты һәм Нариманов урамының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнчыгышка таба Яр Чаллы һәм Тынычлык проспектларының күчәр сызыклары буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Академик Королев урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Академик Королев урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Чулман проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары аны кисеп үтә һәм, Академик Королев урамын дәвам итеп, шул ук юнәлештә Яңа шәһәрнең 37 нче һәм 36 нчы микрорайоннары йортлары арасыннан уза торган автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, 36 нчы микрорайон территориясен кертеп, Раскольников урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Раскольников урамының күчәр сызы-

гы буйлап, сул якта урнашкан территорияне кертеп, Рәис Беляев проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм, Рәис Беляев проспектының күчәр сызыгын дәвам итеп, шул ук юнәлештә автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Раскольников урамы буенча 60 нчы йортның көньягы буйлап Кама елгасының сул ярында (Түбән Кама сусаклагычы) урнашкан шәһәр пляжы территориясенә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм шәһәр пляжының көнчыгыш ягы буйлап «Сан Дали» пляжының көньяк чигенә кадәр уза, алга таба көнбатыш юнәлештә «Сан Дали» пляжының көньяк чиге буйлап, Елга портының йөк причалы территориясен кертеп, яр полосасына кадәр бара, алга таба туп-туры төньяк-көнбатышка таба Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, очлаеп кергән коры җирнең һәм утрауның көнбатыш ягы буйлап Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буенча уза торган «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чигенә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатыш юнәлештә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буенча (Түбән Кама сусаклагычының сул ярының яр сызыгы буйлап) Чаллы шәһәренең Комсомольский һәм Үзәк районнары административ чиге белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба административ чик буйлап Нариманов урамы һәм Чулман проспектының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба көнчыгышка таба Нариманов урамының күчәр сызыгы буйлап Яр Чаллы проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

### 20 нче суд участогы

20 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Халыклар Дуслыгы проспекты һәм Шамил Усманов урамының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнбатышка таба Халыклар Дуслыгы проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Раскольников урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Раскольников урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Рәис Беляев проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Рәис Беляев проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Шамил Усманов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көньяк-көнбатышка таба Шамил Усманов урамының күчәр

сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Халыклар Дуслыгы проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

20 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең көньяк-көнчыгыш өлешендәге сәнәгать-коммуналь зона территориясендә урнашкан басу аша кишәрлек керә, аның чиге Сәнәгать урамы һәм ТЭЦ проездының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнчыгышка таба Сәнәгать урамының күчәр сызыгы буенча, уң якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, Техника урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Техника урамының күчәр сызыгы буенча Металлург урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба Металлург урамының күчәр сызыгы буенча ТЭЦ проезды белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнбатышка таба ТЭЦ проездының күчәр сызыгы буенча Сәнәгать урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 21 нче суд участогы

21 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Академик Королев һәм Шамил Усманов урамнарының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Академик Королев урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Әхмәтшин урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Әхмәтшин урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Кол Гали бульварына кадәр бара, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнбатышка таба Яңа Шәһәрнең 58 нче һәм 59 нчы микрорайоннары торак массивлары арасыннан Кол Гали бульвары буенча уза торган автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, 59 нчы микрорайон территориясен кертеп, Мәскәү проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Мәскәү проспектының күчәр сызыгы буйлап Халыклар Дуслыгы проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба Халыклар Дуслыгы проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Тынычлык проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Тынычлык проспектының күчәр сы-

зыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Рәис Беляев проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Рәис Беляев проспектының күчәр сызыгы буйлап Сөембикә проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары көньяк-көнбатышка таба Сөембикә проспектының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Халыклар Дуслыгы проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Халыклар Дуслыгы проспектының күчәр сызыгы буйлап Шамил Усманов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары көньяк-көнбатышка таба Шамил Усманов урамының күчәр сызыгы буйлап Академик Королев урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

21 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең көньяк-көнчыгыш өлешендәге сәнәгать-коммуналь зона территориясендә урнашкан басу аша кишәрлек керә, аның чиге Минзәлә тракты һәм Хлебный проездының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнчыгышка таба Хлебный һәм Транспорт проездларының күчәр сызыклары буенча, уң якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, Техника урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Техника урамының күчәр сызыгы буйлап Производство проезды белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары көньяк-көнбатышка таба Производство проездының күчәр сызыгы буенча Минзәлә трактының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 22 нче суд участогы

22 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Энергетиклар тыкрыгы һәм Муса Җәлил исемендәге проспектның күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнчыгышка таба Муса Җәлил исемендәге проспектның күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Гидротөзүчеләр урамына кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Гидротөзүчеләр урамының күчәр сызыгы буйлап Гидротөзүчеләр урамы буенча 1 нче йортның төньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм автомобиль юлы буйлап, Гидротөзүчеләр урамы буенча 1 нче һәм Парк тыкрыгы буенча 2 нче йорт-

ларны кертеп, Парк тыкрыгы буенча 4 нче йортның көньяк-көнчыгыш кырыеннан аның көньяк почмагына кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба Парк тыкрыгы буенча 4, 6 һәм 8 нче йортларның көньяк-көнбатыш кырыеннан, Парк тыкрыгы буенча 1 нче йортны кертеп, Парк тыкрыгы буенча 8 нче йортның көнбатыш почмагына кадәр уза, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба әлеге йортның һәм Гидротөзүчеләр урамы буенча 3 нче йортның төньяк-көнбатыш кырыеннан, Гидротөзүчеләр урамы буенча 5 нче йортны кертеп, Гидротөзүчеләр урамының күчәр сызыгы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Гидротөзүчеләр урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Шлюз урамына кадәр уза, алга таба, сул якта урнашкан территорияне кертеп, шул ук юнәлештә 150 метр Шлюз урамының күчәр сызыгы буйлап гаражлар яныннан Түбән Кама сусаклагычының сул ярына кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгыш юнәлештә Түбән Кама сусаклагычының сул ярындагы яр буе полосасы буйлап Мәләкәс елгасы үзәненә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм туры сызык буенча төньяк-көнбатышка таба Кама елгасы фарватеры буйлап уза торган «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чигенә кадәр уза, алга таба көнбатыш юнәлештә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап, Түбән Кама гидроэлектростанциясенең гидротехник корылмалары, Кымыз торак пункты территорияләрен кертеп, Магистраль урамы белән сәнәгать билгеләнешендәге тимер юллар кисешкән җирдә урнашкан «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең көньяк-көнбатыш чигендә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба сәнәгать билгеләнешендәге тимер юлга бүлеп бирелгән полосаның төньягы буйлап, сул якта урнашкан Сидоровка һәм Суар торак пунктлары территорияләрен кертеп, Суар торак пунктының көньяк-көнчыгыш читенә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм төньякка таба грунт автомобиль юлы буенча «Лада-2» гараж-төзелеш кооперативының көньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба «Лада-2» гараж-төзелеш кооперативы һәм Казан проспекты, 3/1 нче йорт адресы буенча урнашкан 132 нче ягулык салу станциясе территорияләре арасыннан, «Лада-2» гараж-төзелеш кооперативы территориясен кертеп, Казан проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Казан проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп,

Мәләкәс елгасы аркылы автомобиль юлы күпере уртасында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары уңга борыла һәм төньяк-көнчыгышка таба Мәләкәс елгасы үзәне буйлап агым буенча аска таба, сул ярны кертеп, Габдулла Тукай исемендәге яр буендагы 14 нче йортның көнчыгыш почмагы янында Мәләкәс елгасының сул ярында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнбатышка таба, Габдулла Тукай исемендәге яр буендагы 14 нче йортны кертеп, әлеге йортның төньяк-көнчыгыш ягы буйлап уза, аннары Габдулла Тукай исемендәге яр буен кисеп үтә һәм алга таба Габдулла Тукай исемендәге яр буендагы 23 нче йортның көньяк-көнбатыш ягы буйлап Энергетиклар тыкрыгына кадәр бара, алга таба шул ук юнәлештә Энергетиклар тыкрыгының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Муса Җәлил исемендәге проспектның күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

## 23 нче суд участогы

23 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Яр Чаллы проспекты һәм Низаметдинов Р.М. исемендәге урамның күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып төньяк-көнчыгышка таба Яр Чаллы проспектының күчәр сызыгы буйлап, сул якта урнашкан ЗЯБ 17А микрорайоны һәм сәнәгать зонасы территорияләрен кертеп, Нариманов урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көнбатыш юнәлештә Нариманов урамының күчәр сызыгы буйлап Чулман проспекты белән кисешкән җиргә кадәр һәм алга таба шул ук юнәлештә Чаллы шәһәренең Комсомольский һәм Үзәк районнары административ чиге буйлап Кама елгасының яр сызыгына (Түбән Кама сусаклагычы) кадәр бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буенча уза торган «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чигенә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатыш юнәлештә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буенча (Түбән Кама сусаклагычының сул ярының яр сызыгы буенча) Мәләкәс елгасы тамагына кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньяк-көнчыгышка таба Мәләкәс елгасы үзәне буенча агымы буйлап өскә таба, сул ярны кертеп, Габдулла Тукай исемендәге яр буендагы 93/100 нче йортның көньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм туры сызык буйлап төньяк-көнбатышка таба Габдулла Тукай исемендәге яр буе белән кисешкән җиргә кадәр уза, аны ки-

сеп үтә һәм шул ук юнәлештә автомобиль юлы буенча Габдулла Тукай исемендәге яр буендагы 83, 91, 89 нчы һәм Муса Җәлил исемендәге проспект буенча 92 нче, 88 нче йортларның төньяк-көнчыгыш кырыеннан, Габдулла Тукай исемендәге яр буендагы 93/100 нче һәм Муса Җәлил исемендәге проспект буенча 96 нчы йортларны кертеп, Муса Җәлил исемендәге проспектның күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгыш юнәлештә Муса Җәлил исемендәге һәм Яр Чаллы проспектларының күчәр сызыклары буйлап Сарман трактына кадәр уза, алга таба көньякка таба Сарман трактының күчәр сызыгы буйлап Маршал Жуков исемендәге урамга кадәр уза, аннары Маршал Жуков исемендәге урамга борыла һәм төньяк-көнчыгыш юнәлештә аның күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Низаметдинов Р.М. исемендәге урам белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнбатышка таба Низаметдинов Р.М. исемендәге урамның күчәр сызыгы буйлап Яр Чаллы проспектының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара.

## 24 нче суд участогы

24 нче суд участогы чигенә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Тынычлык, Яр Чаллы проспектлары һәм Академик Королев урамының күчәр сызыклары киселешендә урнашкан ноктадан алып көньяк-көнчыгышка таба Академик Королев урамының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Әхмәтшин урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Әхмәтшин урамының күчәр сызыгы буйлап, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Кол Гали бульварына кадәр бара, аннары сулга борыла һәм төньяк-көнбатышка таба Яңа шәһәрнең 58 нче һәм 59 нчы микрорайоннары торак массивлары арасыннан Кол Гали бульвары буенча уза торган автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап, 58 нче микрорайон территориясен кертеп, Мәскәү проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Мәскәү проспектының күчәр сызыгы буйлап Халыклар Дуслыгы проспекты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Халыклар Дуслыгы проспектының күчәр сызыгы буйлап, так якта урнашкан йортларны кертеп, Машина төзүчеләр урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба Машина төзүчеләр урамының күчәр сызыгы буйлап,

Яңа шәһәрнең 60 нчы микрорайоны һәм Орловка торак пункты территорияләрен кертеп, «Орловка боҗрасы» автомобиль юллары чишелешендә урнашкан Минзәлә трактының һәм Казан проспектының күчәр сызыклары белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көньяк-көнчыгышка таба Минзәлә трактының күчәр сызыгы буйлап Производство проездына кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Производство проездының күчәр сызыгы буйлап, уң якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, Техника урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба Техника урамының күчәр сызыгы буйлап Сәнәгать урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба Сәнәгать урамының күчәр сызыгы буйлап Минзәлә тракты белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Минзәлә трактының күчәр сызыгы буйлап Металлург урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Металлург урамының күчәр сызыгы буйлап Чаллы – Минзәлә автомобиль юлы (М-7 федераль трассасы) белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көньяк-көнчыгышка таба Чаллы – Минзәлә автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Чаллы – Минзәлә автомобиль юлының көньяк-көнбатыш ягы һәм икенче җылылык чыганагының көньяк-көнчыгыш чиге кисешкән ноктада урнашкан «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чигенә кадәр уза, алга таба көнбатыш юнәлештә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге буйлап Чаллы елгасы һәм Ялхов инеше киселешендә урнашкан ноктага кадәр бара, аннары уңга борыла һәм гомуми юнәлештә төньяк-көнбатышка таба Чаллы елгасы үзәне буенча агым буйлап аска таба, уң ярны (Орловка торак пунктының көньяк читләре) кертеп, Яр Чаллы проспекты буенча урнашкан автомобиль юлы күперенә кадәр уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба Яр Чаллы проспектының күчәр сызыгы буйлап Тынычлык, Яр Чаллы проспектлары һәм Академик Королев урамының күчәр сызыклары кисешкән ноктага кадәр уза.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан шәһәре,
2013 елның 17 апреле
№ 33-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 570. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырыгынчы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырыгынчы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында хисап.
3. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $8^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 480-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
4. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 477-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
5. «Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 452-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
6. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 444-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
7. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 458-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

8. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм референдумнар турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 466-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 470-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Биектау муниципаль районының Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү, аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 1443-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 5.1 һәм 5.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 481-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 488-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 472-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 486-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16. «Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына хайваннар

чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 482-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 19 статьясына үзгәреш кертү турында» 478-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

18. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 485-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

19. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 463-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында.

20. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында.

21. Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкиле Е.А. Кулешовның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.

22. «Россия Федерациясе Җинаять кодексының $282^1$ һәм $282^2$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.

23. Берләшкән Милләтләр Оешмасының 2003 елның 31 октябрендәге Коррупциягә каршы конвенциясенең 20 статьясын ратификацияләү турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында.

24. «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» 229085-6 номерлы федераль закон проекты турында (вазыйфа биләүгә конкурста катнашучы затларны эш белән тәэмин итүдә эш бирүчеләрнең ярдәме хакында).

25. «Балалары булган гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 217934-6 номерлы федераль закон про-

екты турында (ана (гаилә) капиталы акчалары исәбеннән сатып алына торган торак урынына таләпләр билгеләү хакында).

26. Гражданнарның ташламалы категорияләрен шифаханә-курорт юлламалары белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенә Кабарда-Балкар Респуб-ликасы Парламенты мөрәҗәгате хакында.

27. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» Федераль законның 11 статьясына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын кертү буенча Архангельск өлкә депутатлары Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

28. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлардагы урыннар һәм торак йортлар милекчеләренә һәм файдаланучыларына коммуналь хезмәт күрсәтү кагыйдәләрен куллануга коммуналь хезмәтләрнең барлык төрләре буенча гомуми йорт ихтыяҗлары өчен нормативларны куллану өлешендә мораторий кертү турында Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгына Коми Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында.

29. Россия Федерациясе Пенсия фондына шәхси эшкуарлар түли торган иминият кертемнәре күләмнәренең кимүе өлкәсендә федераль законнарны үзгәртү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Төньяк Осетия – Алания Республикасы Парламенты мөрәҗәгате турында.

30. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексы» 246960-6 номерлы федераль закон проекты турында (гомуми юрисдикциядәге судлар тарафыннан административ суд эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен җайга салу).

31. «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 232608-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе гражданнары, карау өчен, үз мөрәҗәгатьләрен җибәрергә хокуклы адресатлар исемлеген киңәйтү өлешендә).

32. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 248585-6 номерлы федераль закон проекты турында (ветеринария өлкәсендә

законнарны бозган өчен административ хокук бозулар составларын төгәлләштерү һәм җаваплылыкны көчәйтү өлешендә).

33. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә аерым федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү турында» 246969-6 номерлы федераль конституциячел закон проекты хакында (Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын кабул итүгә бәйле рәвештә федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү).

34. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 246965-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын кабул итүгә бәйле рәвештә федераль законнарга үзгәрешләр кертү).

35. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең башка закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 241591-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясендә эшкә рөхсәт яисә патент нигезендә хезмәт эшчәнлекләрен гамәлгә ашырырга ниятләгән чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны салым органнарында исәпкә кую механизмын камилләштерү өлешендә, шулай ук Федераль миграция хезмәте органнары һәм Россия Федерациясе салым органнары арасында тиешле белешмәләрне алмашу процедураларын һәм тәртибен оптимальләштерү максатларында).

36. «Корал турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Кабарда-Балкар Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасы турында.

37. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 һәм 8.37 статьяларына һәм Россия Федерациясе Җинаять кодексының 256 статьясына балыкчылык һәм су биологик ресурсларын саклау хакында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү максатларында үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына

кертү буенча Сахалин өлкә Думасының закон чыгару инициативасы хакында.

38. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

39. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 362 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 249584-6 номерлы федераль закон проекты хакында (кыйммәтле транспорт чаралары милекчеләренә салым йөкләмәсен арттыру өлешендә).

40. «Салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычны җайга салу мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 227758-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

41. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның $26^3$ статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мәскәү өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында.

42. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 250003-6 номерлы федераль закон проекты турында (монополиягә каршы законнарны бозган өчен административ җаваплылык билгели торган нигезләмәләрне төгәлләштерү өлешендә).

43. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын гамәлгә кертү тәртибе турында» 246963-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексы кабул ителгәннән һәм гамәлгә кертелгәннән соң гавами хокук мөнәсәбәтләреннән барлыкка килә торган эшләрне судларда карау тәртибе).

44. «Полиция турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 242420-6 номерлы федераль закон проекты турында (хәрби комиссариатка килү өчен чакыру

кәгазьләре бирү максатында гражданнарның яшәү урыннарын билгеләү буенча полициягә йөкләмә бирү өлешендә).

45. «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» 241971-6 номерлы федераль закон проекты турында (аерым категория гражданнарның дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләре тарафыннан чиратсыз рәвештә шәхси кабул ителү хокукын билгеләү өлешендә).

46. «Мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контроле турында һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга ярдәм итү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 239149-6 номерлы федераль закон проекты турында (сәяси партияләргә һәм дини берләшмәләргә иҗтимагый күзәтү комиссиясе составына үз кандидатларын чыгару хокукын бирү өлешендә).

47. «Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашулары турында» 238654-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

48. «Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашулары мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 238639-6 номерлы федераль закон проекты хакында.

49. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 236741-6 номерлы федераль закон проекты турында (хәрәкәт итүне билгеләнгән тизлектән арттырган өчен җаваплылыкны төгәлләштерү хакында).

50. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.22 статьясына үзгәреш кертү хакында» 234583-6 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чараларын дәүләт теркәвенә кую кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыкны арттыру хакында).

51. «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 232405-6 номерлы федераль закон проекты турында (төшенчәләр аппаратын киңәйтү һәм шимбә, якшәмбе һәм бәйрәм көннәрендә иртәнге вакытта тавыш йогынтысының билгеләнгән санитар нормаларының гамәлдә булуын тарату өлешендә).

52. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 231581-6 номерлы федераль закон проекты турында (гавами чараларны

оештыручыларга һәм анда катнашучыларга җаваплылыкны төгәлләштерү өлешендә).

53. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 231292-6 номерлы федераль закон проекты турында (җир законнарын бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында).

54. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 231281-6 номерлы федераль закон проекты турында (коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү күләмен исәпләү тәртибен бозган өчен җаваплылык билгеләү хакында).

55. «Полиция турында» Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлешенә үзгәреш кертү хакында» 223180-6 номерлы федераль закон проекты турында (хәрби исәпкә куелудан, хәрби хезмәткә яисә хәрби җыеннарга чакырудан, хәрби хезмәт яисә хәрби җыеннар узудан качып йөрүче гражданнарны эзләү һәм кулга алуны гамәлгә ашыру буенча полициягә йөкләмә бирү өлешендә).

56. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2855-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 571. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп биш елга түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Арча суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Гыйльмуллина Гүзәлия Фәрт кызын;

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Вахитов суд районы буенча:
3 нче суд участогына – Рәхмәтуллина Ләйсән Хәбибрахман кызын;

Татарстан Республикасы Алабуга суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Лыкова Ольга Станиславовнаны;

Татарстан Республикасы Зәй суд районы буенча:
3 нче суд участогына – Митрофанова Людмила Федоровнаны;

Татарстан Республикасы Зеленодольск суд районы буенча:
5 нче суд участогына – Юнысов Рамил Харис улын;

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Мәскәү суд районы буенча:
3 нче суд участогына – Шәрипова Алсу Әнвәр кызын;
4 нче суд участогына – Сабиров Дамир Рәис улын;
7 нче суд участогына – Саматошенкова Ирина Геннадьевнаны;

Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Гарипов Марсель Идрис улын;

Татарстан Республикасы Түбән Кама суд районы буенча:
3 нче суд участогына – Кожевников Василий Александровичны;
8 нче суд участогына – Щучкина Светлана Павловнаны;

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Яңа Савин суд районы буенча:
3 нче суд участогына – Локманова Анна Анатольевнаны;

Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет суд районы буенча:
4 нче суд участогына – Васильева Марина Робертовнаны;
7 нче суд участогына – Германова Елена Георгиевнаны.

2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә сайланган Рәхмәтуллина Ләйсән Хәбибрахман кызының, Митрофанова Людмила Федоровнаның, Кожевников Василий Александровичның, Локманова Анна Анатольевнаның һәм Васильева Марина Робертовнаның Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары вәкаләтләре чоры аларның моннан алдагы

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вәкаләтләре чоры тәмамланган көннән башлана.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2856-IV ДС

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 572. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2012 елгы эшчәнлеге турында хисап хакында

Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2012 елгы эшчәнлеге турында хисапны «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә карап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2012 елгы эшчәнлеге турында хисапны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2012 елгы эшчәнлеге турында хисап буенча фикер алышу барышында депутат берләшмәләре вәкилләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәрне, карау һәм кирәкле чаралар кабул итү өчен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының 2012 елгы эшчәнлеге турында хисапны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми сайтына куюны тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2857-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 573. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $8^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 480-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $8^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 480-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2013 елның 27 апрелендә 13.00 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2013 елның 27 апрелендә 13.30 сәгатькә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2858-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 574. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 8[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 480-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 8[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 480-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2859-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 575. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 8[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (480-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 8[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (480-4 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2860-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 576. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 477-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 477-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына күрсәтелгән закон проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына өченче укылышта карауга кертергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2861-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 577. «Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 452-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 452-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2862-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 578. «Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (452-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (452-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2863-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 579. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 444-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 444-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты күрсәтелгән закон проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына өченче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2864-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 580. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 458-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 458-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты күрсәтелгән закон проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына өченче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2865-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 581. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм референдумнар турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 466-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм референдумнар турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 466-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр 2013 елның 27 маена кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты күрсәтелгән закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2013 елның 27 июненә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2866-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 582. «Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 470-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы тарафыннан кертелгән «Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 470-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2867-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 583. «Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (470-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (470-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2868-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 584. «Биектау муниципаль районының Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү, аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 1443-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы тарафыннан кертелгән «Биектау муниципаль районының Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү, аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 1443-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2869-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 585. «Биектау муниципаль районының Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү, аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (1443-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Биектау муниципаль районының Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү, аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (1443-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2870-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 586. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 5.1 һәм 5.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 481-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты К.Ю. Пузырьков тарафыннан кертелгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 5.1 һәм 5.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 481-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына 2013 елның 27 маена кадәр кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты күрсәтелгән закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2013 елның 27 июненә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2871-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 587. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 489-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты тарафыннан кертелгән «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының

19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 489-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2872-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 588. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (489-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (489-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2873-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 589. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 488-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Ш.Ш. Яһудин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 488-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2013 елның 20 маена кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2013 елның 27 маена кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**
Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2874-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 590. «Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 472-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 472-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**
Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2875-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 591. «Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (472-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (472-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2876-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 592. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 486-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 486-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2877-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 593. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (486-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (486-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2878-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 594. «Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 482-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары В.П. Васильев, И.М.Сафиуллин тарафыннан кертелгән «Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен

кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 482-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2879-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 595. «Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (482-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (482-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2880-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 596. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 19 статьясына үзгәреш кертү турында» 478-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 19 статьясына үзгәреш кертү турында» 478-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2881-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 597. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 19 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (478-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 19 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын (478-4 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2882-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 598. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 485-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 485-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр 2013 елның 17 маена кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты күрсәтелгән закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2013 елның 31 маена кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2883-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 599. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 463-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 463-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проек-

тына төзәтмәләрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына кертү вакытын 2013 елның 21 июненә кадәр озайтырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты күрсәтелгән закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2013 елның 21 сентябренә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2884-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 600. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән карар проектына төзәтмәләр 2013 елның 15 маена кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты әлеге карар проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2013 елның 30 маена кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2885-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 601. Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкиле Е.А. Кулешовның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең 10 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкиле Е.А. Кулешовның вәкаләтләре, аның вафат булуы сәбәпле, 2013 елның 11 февраленнән вакытыннан алда туктатылган дип санарга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2886-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 602. «Россия Федерациясе Җинаять кодексының $282^1$ һәм $282^2$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Җинаять кодексының $282^1$ һәм $282^2$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.

2. «Россия Федерациясе Җинаять кодексының $282^1$ һәм $282^2$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын, рәсми бәяләмәләр алу өчен, Россия Федерациясе Хөкүмәтенә һәм Россия Федерациясе Югары Судына җибәрергә.

3. «Россия Федерациясе Җинаять кодексының $282^1$ һәм $282^2$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең һәм Россия Федерациясе Югары Судының рәсми бәяләмәләрен алганнан соң, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

4. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Татарстан Республикасында сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

5. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында күрсәтелгән федераль закон проектын караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми вәкилләре итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Ришат Фазлетдин улы Әбүбакировны һәм Татарстан Республикасы юстиция министры Мидхәт Мәсхүт улы Кормановны билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2887-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 603. «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» 229085-6 номерлы федераль закон проекты турында (вазыйфа биләүгә конкурста катнашучы затларны эш белән тәэмин итүдә эш бирүчеләрнең ярдәме хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» 229085-6 номерлы федераль закон проектын (вазыйфа биләүгә конкурста катнашучы затларны эш белән тәэмин итүдә эш бирүчеләрнең ярдәме хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2888-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 604. «Балалары булган гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 217934-6 номерлы федераль закон проекты турында (ана (гаилә) капиталы акчалары исәбеннән сатып алына торган торак урынына таләпләр билгеләү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Балалары булган гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 217934-6 номерлы федераль закон проектын (ана (гаилә) капиталы акчалары исәбеннән сатып алына торган торак урынына таләпләр билгеләү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2889-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 605. Гражданнарның ташламалы категорияләрен шифаханә-курорт юлламалары белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенә Кабарда-Балкар Республикасы Парламенты мөрәҗәгате хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Гражданнарның ташламалы категорияләрен шифаханә-курорт юлламалары белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенә Кабарда-Балкар Республикасы Парламенты мөрәҗәгатен хупларга.

2. Әлеге карарны Кабарда-Балкар Республикасы Парламентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2890-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 606. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» Федераль законның 11 статьясына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын кертү буенча Архангельск өлкә депутатлары Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» Федераль законның 11 статьясына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын кертү буенча Архангельск өлкә депутатлары Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына, Архангельск өлкә депутатлары Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2891-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 607. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлардагы урыннар һәм торак йортлар милекчеләренә һәм файдаланучыларына коммуналь хезмәт күрсәтү кагыйдәләрен куллануга коммуналь хезмәтләрнең барлык төрләре буенча гомуми йорт ихтыяҗлары өчен нормативларны куллану өлешендә мораторий кертү турында Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгына Коми Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлардагы урыннар һәм торак йортлар милекчеләренә һәм файдаланучыларына коммуналь хезмәт күрсәтү кагыйдәләрен куллануга коммуналь хезмәтләрнең барлык төрләре буенча гомуми йорт ихтыяҗлары өчен нормативларны куллану өлешендә мораторий кертү турында Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгына Коми Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен хупларга.

2. Әлеге карарны Коми Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2892-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 608. Россия Федерациясе Пенсия фондына шәхси эшкуарлар түли торган иминият кертемнәре күләмнәренең кимүе өлкәсендә федераль законнарны үзгәртү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Төньяк Осетия – Алания Республикасы Парламенты мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Россия Федерациясе Пенсия фондына шәхси эшкуарлар түли торган иминият кертемнәре күләмнәренең кимүе өлкәсендә федераль законнарны үзгәртү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Төньяк Осетия – Алания Республикасы Парламенты мөрәҗәгатен хупларга.

2. Әлеге карарны Төньяк Осетия – Алания Республикасы Парламентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2893-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 609. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексы» 246960-6 номерлы федераль закон проекты турында (гомуми юрисдикциядәге судлар тарафыннан административ суд эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен җайга салу)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексы» 246960-6 номерлы федераль закон проектын (гомуми юрисдикциядәге судлар тарафыннан административ суд эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен җайга салу) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2894-IV ДС

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 610. «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 232608-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе гражданнары, карау өчен, үз мөрәҗәгатьләрен җибәрергә хокуклы адресатлар исемлеген киңәйтү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 232608-6 номерлы федераль закон проектын (Россия Федерациясе гражданнары, карау өчен, үз мөрәҗәгатьләрен җибәрергә хокуклы адресатлар исемлеген киңәйтү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2895-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 611. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 248585-6 номерлы федераль закон проекты турында (ветеринария өлкәсендә законнарны бозган өчен административ хокук бозулар составларын төгәлләштерү һәм җаваплылыкны көчәйтү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 248585-6 номерлы федераль закон проектын (ветеринария өлкәсендә законнарны бозган өчен административ хокук бозулар составларын төгәлләштерү һәм җаваплылыкны көчәйтү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2896-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 612. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә аерым федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү турында» 246969-6 номерлы федераль конституциячел закон проекты хакында (Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын кабул итүгә бәйле рәвештә федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә аерым федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү турында» 246969-6 номерлы федераль конституциячел закон проектын (Россия Федерация-

се Административ суд эшчәнлеге кодексын кабул итүгә бәйле рәвештә федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2897-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 613. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 246965-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын кабул итүгә бәйле рәвештә федераль законнарга үзгәрешләр кертү)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 246965-6 номерлы федераль закон проектын (Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын кабул итүгә бәйле рәвештә федераль законнарга үзгәрешләр кертү) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2898-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**614. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең башка закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 241591-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясендә эшкә рөхсәт яисә патент нигезендә хезмәт эшчәнлекләрен гамәлгә ашырырга ниятләгән чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны салым органнарында исәпкә кую механизмын камилләштерү өлешендә, шулай ук Федераль миграция хезмәте органнары һәм Россия Федерациясе салым органнары арасында тиешле белешмәләрне алмашу процедураларын һәм тәртибен оптимальләштерү максатларында)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең башка закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 241591-6 номерлы федераль закон проектын (Россия Федерациясендә эшкә рөхсәт яисә патент нигезендә хезмәт эшчәнлекләрен гамәлгә ашырырга ниятләгән чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны салым органнарында исәпкә кую механизмын камилләштерү өлешендә, шулай ук Федераль миграция хезмәте органнары һәм Россия Федерациясе салым органнары арасында тиешле белешмәләрне алмашу процедураларын һәм тәртибен оптимальләштерү максатларында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2899-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**615. «Корал турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Кабарда-Балкар Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасы турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Корал турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Кабарда-Балкар Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Кабарда-Балкар Республикасы Парламентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2900-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 616. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 һәм 8.37 статьяларына һәм Россия Федерациясе Җинаять кодексының 256 статьясына балыкчылык һәм су биологик ресурсларын саклау хакында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү максатларында үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Сахалин өлкә Думасының закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 һәм 8.37 статьяларына һәм Россия Федерациясе Җинаять кодексының 256 статьясына балыкчылык һәм су биологик ресурсларын саклау хакында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү максатларында үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Сахалин өлкә Думасының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Сахалин өлкә Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2901-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 617. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2902-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 618. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 362 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 249584-6 номерлы федераль закон проекты хакында (кыйммәтле транспорт чаралары милекчеләренә салым йөкләмәсен арттыру өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 362 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 249584-6

номерлы федераль закон проектын (кыйммәтле транспорт чаралары милекчеләренә салым йөкләмәсен арттыру өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2903-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 619. «Салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычны җайга салу мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 227758-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычны җайга салу мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 227758-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2904-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 620. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның $26^3$ статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мәскәү өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның $26^3$ статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мәскәү өлкә Думасының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Мәскәү өлкә Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2905-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 621. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 250003-6 номерлы федераль закон проекты турында (монополиягә каршы законнарны бозган өчен административ җаваплылык билгели торган нигезләмәләрне төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 250003-6 номерлы федераль закон проектын (монополиягә каршы законнарны бозган өчен административ җаваплылык билгели торган нигезләмәләрне төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2906-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 622. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын гамәлгә кертү тәртибе турында» 246963-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексы кабул ителгәннән һәм гамәлгә кертелгәннән соң гавами хокук мөнәсәбәтләреннән барлыкка килә торган эшләрне судларда карау тәртибе)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын гамәлгә кертү тәртибе турында» 246963-6 номерлы федераль закон проектын (Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексы кабул ителгәннән һәм гамәлгә кертелгәннән

соң гавами хокук мөнәсәбәтләреннән барлыкка килә торган эшләрне судларда карау тәртибе) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2907-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 623. «Полиция турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 242420-6 номерлы федераль закон проекты турында (хәрби комиссариатка килү өчен чакыру кәгазьләре бирү максатында гражданнарның яшәү урыннарын билгеләү буенча полициягә йөкләмә бирү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Полиция турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 242420-6 номерлы федераль закон проектын (хәрби комиссариатка килү өчен чакыру кәгазьләре бирү максатында гражданнарның яшәү урыннарын билгеләү буенча полициягә йөкләмә бирү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2908-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 624. «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» 241971-6 номерлы федераль закон проекты турында (аерым категория гражданнарның дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләре тарафыннан чиратсыз рәвештә шәхси кабул ителү хокукын билгеләү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» 241971-6 номерлы федераль закон проектын (аерым категория гражданнарның дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләре тарафыннан чиратсыз рәвештә шәхси кабул ителү хокукын билгеләү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2909-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 625. «Мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контроле турында һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга ярдәм итү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 239149-6 номерлы федераль закон проекты турында (сәяси партияләргә һәм дини берләшмәләргә иҗтимагый күзәтү комиссиясе составына үз кандидатларын чыгару хокукын бирү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контроле турында һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга ярдәм итү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 239149-6 номерлы федераль закон проектын (сәяси партияләргә һәм дини берләшмәләргә иҗтимагый күзәтү комиссиясе составына үз кандидатларын чыгару хокукын бирү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2910-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 626. «Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашулары турында» 238654-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашулары турында» 238654-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**
Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2911-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 627. «Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашулары мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 238639-6 номерлы федераль закон проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:
1. «Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашулары мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 238639-6 номерлы федераль закон проектын хупларга.
2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**
Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2912-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 628. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 236741-6 номерлы федераль закон проекты турында (хәрәкәт итүне билгеләнгән тизлектән арттырган өчен җаваплылыкны төгәлләштерү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:
1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 236741-6 номерлы федераль закон проектын (хәрәкәт итүне билгеләнгән

тизлектән арттырган өчен җаваплылыкны төгәлләштерү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2913-IV ДС

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 629. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.22 статьясына үзгәреш кертү хакында» 234583-6 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чараларын дәүләт теркәвенә кую кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыкны арттыру хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.22 статьясына үзгәреш кертү хакында» 234583-6 номерлы федераль закон проектын (транспорт чараларын дәүләт теркәвенә кую кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыкны арттыру хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2914-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 630. «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 232405-6 номерлы федераль закон проекты турында (төшенчәләр аппаратын киңәйтү һәм шимбә, якшәмбе һәм бәйрәм көннәрендә иртәнге вакытта тавыш йогынтысының билгеләнгән санитар нормаларының гамәлдә булуын тарату өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 232405-6 номерлы федераль закон проектын (төшенчәләр аппаратын киңәйтү һәм шимбә, якшәмбе һәм бәйрәм көннәрендә иртәнге вакытта тавыш йогынтысының билгеләнгән санитар нормаларының гамәлдә булуын тарату өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2915-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 631. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 231581-6 номерлы федераль закон проекты турында (гавами чараларны оештыручыларга һәм анда катнашучыларга җаваплылыкны төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 231581-6 номерлы федераль закон проектын (гавами чараларны оештыручы-

ларга һәм анда катнашучыларга җаваплылыкны төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2916-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 632. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 231292-6 номерлы федераль закон проекты турында (җир законнарын бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 231292-6 номерлы федераль закон проектын (җир законнарын бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2917-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 633. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 231281-6 номерлы федераль закон проекты турында (коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү күләмен исәпләү тәртибен бозган өчен җаваплылык билгеләү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 231281-6 номерлы федераль закон проектын (коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү күләмен исәпләү тәртибен бозган өчен җаваплылык билгеләү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2918-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 634. «Полиция турында» Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлешенә үзгәреш кертү хакында» 223180-6 номерлы федераль закон проекты турында (хәрби исәпкә куелудан, хәрби хезмәткә яисә хәрби җыеннарга чакырудан, хәрби хезмәт яисә хәрби җыеннар узудан качып йөрүче гражданнарны эзләү һәм кулга алуны гамәлгә ашыру буенча полициягә йөкләмә бирү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Полиция турында» Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлешенә үзгәреш кертү хакында» 223180-6 номерлы федераль закон проектын (хәрби исәпкә куелудан, хәрби хезмәткә яисә хәрби җыеннарга чакырудан, хәрби хезмәт яисә

хәрби җыеннар узудан качып йөрүче гражданнарны эзләү һәм кулга алуны гамәлгә ашыру буенча полициягә йөкләмә бирү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2919-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 635. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Х.Г. Миргалимовның депутат гарызнамәсе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Тарловка» туберкулезга каршы шифаханәсен юк итүнең законлылыгын тикшерү турындагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Х.Г. Миргалимов гарызнамәсен Татарстан Республикасы Премьер-министры И.Ш. Халиковка җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 27 апреле
№ 2920-IV ДС

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 636. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырыгынчы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырыгынчы утырышын 2013 елның 27 апрелендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары А.П. Гусев**

Казан шәһәре
2013 елның 18 апреле
№ 2851-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 637. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырыгынчы утырышы каравына кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырыгынчы утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында хисап.

3. «Татарстан Республикасында халыкны адреслы социаль яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $8^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 480-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

4. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 477-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

5. «Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 452-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

6. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 444-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

7. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 458-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

8. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм референдумнар турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 466-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 470-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Биектау муниципаль районының Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү, аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 1443-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 5.1 һәм 5.2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 481-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 488-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 472-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 486-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16. «Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 482-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 19 статьясына үзгәреш кертү турында» 478-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

18. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 485-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

19. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында.

20. Татарстан Республикасы судьяларының Квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкиле Е.А. Кулешовның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.

21. «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 25 статьясына

үзгәреш кертү хакында» 229085-6 номерлы федераль закон проекты турында (вазыйфа биләүгә конкурста катнашучы затларны эш белән тәэмин итүдә эш бирүчеләрнең ярдәме хакында).

22. «Балалары булган гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 217934-6 номерлы федераль закон проекты турында (ана (гаилә) капиталы акчалары исәбеннән сатып алынган торак урынына таләпләр билгеләү хакында).

23. Гражданнарның ташламалы категорияләрен шифаханә-курорт юлламалары белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенә Кабарда-Балкар Республикасы Парламенты мөрәҗәгате хакында.

24. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм турында» Федераль законның 11 статьясына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын кертү буенча Архангельск өлкә депутатлары Җыелышының закон чыгару инициативасы турында.

25. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлардагы урыннар һәм торак йортлар милекчеләренә һәм файдаланучыларына коммуналь хезмәт күрсәтү кагыйдәләрен куллануга коммуналь хезмәтләрнең барлык төрләре буенча гомуми йорт ихтыяҗлары өчен нормативларны куллану өлешендә мораторий кертү турында Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгына Коми Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында.

26. Россия Федерациясе Пенсия фондына шәхси эшкуарлар түләгән иминият кертемнәре күләмнәренең кимүе өлкәсендә федераль законнарны үзгәртү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Төньяк Осетия – Алания Республикасы Парламенты мөрәҗәгате турында.

27. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексы» 246960-6 номерлы федераль закон проекты турында (гомуми юрисдикциядәге судлар тарафыннан административ суд эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен җайга салу).

28. «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 232608-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе гражданнарының карау өчен үз

мөрәҗәгатьләрен җибәрергә хокуклы адресатлар исемлеген киңәйтү өлешендә).

29. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 248585-6 номерлы федераль закон проекты турында (ветеринария өлкәсендә законнарны бозган өчен административ хокук бозулар составларын төгәлләштерү һәм җаваплылыкны көчәйтү өлешендә).

30. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә аерым федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү турында» 246969-6 номерлы федераль конституциячел закон проекты хакында (Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын кабул итүгә бәйле рәвештә федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү).

31. «Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын гамәлгә кертүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 246965-6 номерлы федераль конституциячел закон проекты хакында (Россия Федерациясе Административ суд эшчәнлеге кодексын кабул итүгә бәйле рәвештә федераль законнарга үзгәрешләр кертү).

32. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең башка закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 241591-6 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясендә эшкә яисә патентка рөхсәт нигезендә хезмәт эшчәнлекләрен гамәлгә ашырырга ниятләгән чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны салым органнарында исәпкә кую механизмын камилләштерү өлешендә, шулай ук Федераль миграция хезмәте органнары һәм Россия Федерациясе салым органнары арасында тиешле белешмәләрне алмашу процедураларын һәм тәртибен оптимальләштерү максатларында).

33. «Корал турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Кабарда-Балкар Республикасы Парламентының закон чыгару инициативасы турында.

34. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 һәм 8.37 статьяларына һәм Россия Федерациясе Җинаять кодексының 256 статьясына балыкчылык һәм су биологик ресурсларын саклау хакында Россия Федерациясе

законнарын бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү максатларында үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Сахалин өлкә Думасының закон чыгару инициативасы хакында.

35. «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

36. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары А.П. Гусев**

Казан шәһәре,
2013 елның 18 апреле
№ 2852-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 638. С.М. Захарованы «Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» мактаулы исемен бирүгә тәкъдим итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе Светлана Михайловна Захарованы сәламәтлек саклау өлкәсендәге озак еллар намуслы хезмәте һәм югары казанышлары өчен «Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре» мактаулы исеме бирүгә тәкъдим итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары А.П. Гусев**

Казан шәһәре,
2013 елның 18 апреле
№ 2854-IV ДС